Флёра Тарханова

# Яшьлек эзем калган сукмаклар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Т 21

**Тарханова Флёра**

Т 21 Яшьлек эзем калган сукмаклар: Шигырьләр, җырлар, поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 223 бит.

Җыентыкка шагыйрәнең лирик-фәлсәфи шигырьләре, җырлары һәм поэмалары тупланды.

ISBN 5-298-04172-8 © Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Тарханова Флёра, 2005



# И Туган як!

# I

*И туган як, син – җырымда,*
*Мәңге кайнар канымда,*
*Телгәләнгән йөрәгемдә,*
*Сагыш тулы җанымда!*

# Яуширмә*

*(Җыр)*

Яуширмәгә янә кайттым,
Ак чәчкәле яз килгәч,
Күңелемә моңнар тулды,
Авылымны күргәч.

Күз алдымнан мәңге китмәс
Алмагачлы күлләре,
Җиләк җыйган яланнары,
Йөгереп менгән үрләре.

Кушымта:
Туган авылым Яуширмә,
Ташлап киттең диеп рәнҗемә.
Онытып булмый сине, гүзәл җирем,
Мәңге йөрәгемдә бит син минем,
Онытып булмый сине, изге җирем,
Мәңге калдың йөрәгемдә минем.

Авылым данын күтәрде
Мәшһүр Гаяз Исхакый,
Яугир егетләрен халкым
Күңелендә саклый.

Минем дә язмышым синдә —
Мин синең газиз балаң,
Сиңа кайтсам, и туган як,
Мәңге яшьлектә калам.

Кушымта.

*2001*

---

* Луиза Батыр-Болгари музыкасы.

# Сагыш

Яуширмәдән урап искән җилләр
Тәрәзәмә килеп кагылды,
Озакладың, бер кайтып күр, диеп,
Ишегемнән кереп сарылды.

Ташладым да бөтен эшләремне,
Чыгып киттем Чистай ягына.
Әллә нишләп күңел хискә тулды —
Әллә авылым шулай сагына,
Әллә үзем аны сагынам.

Кайтып кердем, өйгә сәлам бирдем,
Тәрәзләрдә кояш яктысы.
Бер хәл алгач, чыктым урамнарга —
Кәефемне төшереп сискәндерде
Авылымның шактый ят төсе.

Күперләргә таба төшеп киттем,
Әйләним дип күлле «Дыбрау»[1]дан.
Миңа таныш эзләр күреп шулчак,
Сыгылып төштем җаным сыкраудан.

Яр буеның туфрак катламыннан
Мин аларны озак күзләдем:
Болар — минекеләр, Илдуснык

ы бусы,
Сәрия белән Алсу ... эзләре.

Менә алар, менә ярылып ята —
Һич шаярмый әйткән сүзләр бу.
Яр астында йомшак җиргә батып,
Яшеренеп калган эзләр бу.

[1] «Д ы б р а у» (Дубрава) — кайчандыр имәнлек булган.

Шуннан киттем ындыр табагына
(Искә төште студент елларым),
Алмагачлы күлне карап килдем,
Ханнар буасын[1] да буйладым.

Хисләремне төйнәп, яшьлегемне
Эзләп киттем инде клубка.
Ул да башка. Безнең эзләр калган
Клуб ишелеп төшкән без юкта.

Чү! Нәрсә бу? Әллә саташаммы?
Күзләремне пәрдә каплады:
Яшь чактагы клуб сәхнәсенә
Сабыр гына берәү атлады.
Гыйшкым ич бу: моңлы тавышы белән
Миңа атап җырын башлады:

«...Шушындый матур кичләрдә
Кайда йөрдең, гүзәлем?
Бары синең өчен генә
Өзелә бит үзәгем.

Әйтмәсәм дә аңларсыңмы
Өзелеп сөйгәнемне?
Төнбоек чәчәге кебек
Ач миңа йөрәгеңне».

(Аның шушы җыры йөрәгемдә
Бөелеп тора гомер буена.
Үзе әле, исендәдер, диеп
Кертмәгәндер хәтта уена.

[1] Риваятьләргә караганда, борын заманда тархан биләмәсенә кергән күл. Әле һаман да бар (Шәйхи урманына бара торган юл өстендә).

Яра калды, барыбер калды яра:
Кайт, дигәндә, никтер кайтмадым.
Соңгы тапкыр суырып үпкән тәмен
Иренемдә мәңге сакладым.)

Сыктый-сыктый чыктым аргы якка —
Мәктәп юлын күрми түзмәмен.
Зур күперне үтеп, тау менгәндә
Үсмер чакларымны эзләдем.

Кырмавыклар[1] баскан ул тирәне —
Егылырлык хәтта сөртенеп.
Без укыган мәктәп урынында
Кычытканнар үсә гөр килеп.

Уйга чумып күбрәк йөргән саен,
Күләгәләр арта йөземдә.
Кычытканлы шушы сукмакларда
Әти белән әни эзе дә.

Аннан киттем Кади чишмәсенә,
Инеш буйлап Шанга атладым.
Очрамасмы диеп өзелсәм дә,
Үсмер чакларымны тапмадым.

Тапмадым мин гүзәл яшьлекне дә,
Эзләсәм дә авыл бетереп.
Кәефем китеп, өйгә борылып кайттым —
Бар да калган матур төш кебек.

[1] Тигәнәкнең мишәр варианты.

Үткәннәрне барлап кайтыйм диеп,
Багышладым бөтен көнемне.
Күрешүләр көткән идем, ләкин
Сагыш кына басты күңелне.

Гомерләрне тиз үткәрә икән
Салмак кебек тоелган бу агыш.
Олыгайган саен бәгырьләрне
Өтә икән, өтә бу сагыш.

*2003*

# Гармун*

*(Җыр)*

*Әтием истәлегенә*

Өздереп уйнап,
Төнгә таратты
Синең көйләрне бер гармун,
Үзәк-бәгырьгә
Төшеп шул чакны,
Агылды ургып сихри моң.

К у ш ы м т а :
Тукта, гармун, җитте, уйнама,
Күңелләргә салдың мең яра.
Юксынулардан аккан күз яше
Әрнү өстәп бәгырьгә тама.

Төнге урамга
Яткан шушы моң
Кайтарды мине яшь чакка,
Тыелып кына
Кушылып сиңа
Җырлый идем мин кайчакта.

К у ш ы м т а .

Калды көйләрең,
Йөрәк серләрең
Сайрар гармунның телендә,
Сагыну җырларын
Өзелеп уйнавың
Онытылмый әле бүген дә.

К у ш ы м т а .

*2001*

---

* Габдерәзак Мингалиев музыкасы.

## Әниемнең авыру хәбәре

Һич аяусыз кими санау еллар —
Узып булмас узган кадәре...
Таңнарымнан алып чыгып китте
Әниемнең авыру хәбәре.

Гомерләрнең тынгысызын үтте —
Эштә булды узган кадәре...
Йөрәгемне телеп тозлар сипте
Әниемнең авыру хәбәре.

Савыктыру өчен әллә ниләр
Бирер идем таулар кадәре...
Чартлап суккан яшен кебек булды
Әниемнең авыру хәбәре.

Башта — давыл, җанда — өермәләр:
Ник әйтмәгән моңа кадәре?!
Сөендерсен иде Ходаемның
Сәламәт ул дигән хәбәре.

*2001*

## Алсу сеңлемә

Үзәкләргә үтеп юксындыра
Чыр-чу килеп үскән заманнар.
Ни кызганыч: алар, кайтмас булып,
Гасыр аръягында калганнар.

Хәтер-хатирәгә уелып кергән
Бала чакның һәрбер мизгеле
Аермачык булып чагылып уза —
Әйтерсең лә күңел — көзгеле:

Мин — олы кыз. Әүвәл миңа төште
Гаиләнең авыр эшләре.
Берәр потлы чиләкләрен аскан
Көянтә дә иңнән төшмәде.

Унике җан кигән киемнәрне,
Урын-җирне юып элгәчтен,
Зур бер җиңү хисе били иде,
Йорт[1] тутырып тезелешкән бауда
Кибеп яткан керне күргәчтен.

Әни белән юган булсак башта
Бу керләрне алмаш-тилмәштән,
Үсә төшкәч, син ярдәмгә кердең —
Аннан өчәү юдык өемнәрне,
Өч ләгәнне куеп беррәттән.

Хәтерлимсең өйләр җыйган чакны?
Әлфия апа, Илһам Шакирларның
Зур тәлинкәләрен җибәреп,
Шул моңнарга чумып йөзә-йөзә,
Гөлләр итә идек бүлмәне.

[1] Й о р т *(мишәрчә)* — ишегалды.

Аннан китә Мирей Матье белән
Азнавур, Ив Монтан[1] җырлары.
Безнең белән бергә бу җырларны
Бөтен күрше-күлән тыңлады.

Без аларга күмелеп, бала чактан
Сәхнәләрдә җырлап-биедек.
Гомер буе бергә яшәрбез күк,
Мәңге таралышмас күк идек.

Үтте-китте бар да бер мизгелдәй,
Риза булмый моңа — аң дулый.
Бала чакка эзләр юклыгыннан
Йөрәк-бәгырь өзелеп, җан елый.

Еллар кырыс:
Бер ояда үсеп очканны да
Үзгәртә дә куя үзенчә.
Бер үк нәрсә, бер үк хисләр никтер,
Кабул ителә башлый төрлечә,
Кичерелә хәтта төрлечә.

Син дә хәзер бераз бүтәнчәрәк —
Рухи дөньяң бераз икенче:
Милләт рухы, милли хисләр синдә
Кимеп бара кебек шикелле.

Ни дисәң дә, безне бәйли торган,
Якынайта торган җепләр нык:
Әти-әни, туган туфрак аша
Каныбызга сеңгән туганлык.

Шул туганлык хисе югалмасын,
Кемнәр арасында торсаң да.
Нәсел-нәсәбеңнән аерылма,
Чит-ят белән гаилә корсаң да...

---

[1] Француз җырчылары.

Әле кайчан гына яшь-яшь идек —
Бер җитдилек кунды йөзләргә,
Күзлеге дә менде күзләргә.
Мәгънәле сүз генә сөйләшәбез
Урын куймый ялган сүзләргә.

Инде күптән дәү әниләр булып,
Гомерләрне узып барабыз.
Ә шулай да тормыш дәрьясында
Әле һаман юллар ярабыз.

*2004*



# Кӱнелемне борчый...

## II

*Күңелемне борчый мең сорау –*
*Табып бетереп булмый җавапны:*
*Нигә тормыш болай катлаулы да*
*Нигә язмыш болай газаплы?*

# Бөек идеяләр чоры узды

Бөек идеяләр чоры узды —
Челпәрәмә килде дөньясы.
Ил әйләнде тоташ бер мәхшәргә,
Бөтен җирдә козгын оясы.

Элек күзен карга чукымады
Үзе кебек башка карганың.
Бүгенгеләр исә шундук сата,
Йөрсә дә дустым дип карганып.

Бөтен нәрсә җирдә нык болганды:
Ни бер тәртибе юк, ни закон.
Инде бары корал белән генә
Хәл итәләр тормыш низагын.

Бер-беренең малын гына түгел,
Җанын алып килә әвәрә.
Шул козгыннар үткән һәрбер юлда
Канлы күзләр кала тәгәрәп.

Нәрсә булды безнең бу дөньяга —
Нигә сыймый аңа бу халык,
Тынычлыкта рәхәт яшәмичә,
Нигә йөри һаман буталып?

Идеягә кайтыргадыр, бәлки:
Үрчетмәскә үләт козгынын,
Күрмәс өчен хәтта якын дустын
Кыеп йөргән фәхеш тузгынын.

Бөек идеяләр чоры узды —
Челпәрәмә килде дөньясы.
Баткаклыктан торган бу тормышка
Кирәктер, шәт, нокта куясы.

*2003*

# Мин кайтарыр идем...

Хәлләремнән килсә,
Мин кайтарыр идем
Исхакыйлар, Тукай заманын,
Милли горурлыкның
Көчле ташкыныннан
Кайнап торган шәһри Казанын.

Мин кайтарыр идем
Милли әхлаклыкны,
Борынгыдан килгән әдәпне,
Сөрер идем җирдән
Телне, милләтемне
Караллтучы барча гадәтне.

Мин кайтарыр идем
Халкым зыялыгын,
Абруй саклап мәгъруР йөрүне.
Хәтер калганда да,
Үчкә юл куймыйча,
Вәкарь белән китә белүне.

Хәлләремнән килсә,
Мин кайтарыр идем
Исхакыйлар, Тукай заманын —
Хыялымда йөргән
Бары шул гасырда
Күңел тынычлыгын табамын.

*2003*

# Унтугызынчы йөз кешесемен

Унтугызынчы йөз кешесемен —
Яшәр идем тик шул гасырда,
Хөсетле һәм чирле яңа чорга
Куркам хәтта аяк басырга.

Авызын ачса, нәҗес коела торган
Кеше белән тулды дөньясы.
Җебеп калганнарны көч һәм акча
Буйсындырып үзенә кол ясый.

Итагатьле, матур сүзләр генә
Ишетәсе килә һәрвакыт.
Ана сөте керми калгангадыр,
Бик күпләрнең сөйләм, тел ватык.

Яңа туган баласына кадәр
Телен ача ямьсез сүз белән.
Шундый мирас калдыручы затлар
Карый икән нинди күз белән?

Уйлый микән киләчәкне күреп,
Халык эчтән череп бетә дип?
Вакытында туктап юл алмаса,
Баткаклыкка кереп китә бит.

Бабаларым корган дөньяларны,
Нәсел йортын шуңа сагынам.
Шул гасырга кире кайтыйм, дисәм,
Кантарларга килеп абынам.

*2003*

# Ханбикәне «уйнап» булмады

Актриса булам, дия идем,
Зур-зур сәхнәләрдә уйнармын.
(Бу уйларым иң татлысы иде
Бала чакта йөрткән уйларның).

Хыялымнан соңрак ваз кичтем мин,
Әллә инде күреп туйганмын.
Әмма Ходай кушып бу теләкне
Язмышыма язып куйганмын.

Шуңа күрә әллә ничә тапкыр
Хәсрәт сәхнәсендә «уйнадым».
Вакыт-вакыт җанны боз төрсә дә,
Якты дөньялардан туймадым.

Әле уңнан, әле сул ягымнан
Бәргәләде язмыш гөрзие.
Йөзтүбәнләп барыбер төшмәдем мин —
Янда булды ярдәм көрсие[1].

Шул көрсигә утырып хәл алдым да
Дәвам иттем тормыш сукмагын.
Михнәтләрдән буын ныгып калды —
Инде сизмим язмыш тукмавын.

Еллар буе гел каезлый торгач,
Каешланып бетте җилкә дә:
Үзем генә түгел, балалар да
Әле һаман минем җилкәдә.

---

[1] Көрси – кәнәфи, тәхет.

Кырыс тормыш бик нык талкыса да,
Саклый алдым нәсел сыйфатын.
Һаман аңа кушылып йөргәнгәме,
Җиңел үттем байтак юл чатын.

Бала чакның күпме уй-хыялы
Исәпләнде, санга тулмады:
Иң зур хыял чынга ашмый калды —
Канга сеңгән зыялыкны кушып,
Ханбикәне «уйнап» булмады.

*2005*

## Күзләремә һаман яшь тула

Кайвакыт син артык кырыс, диләр —
Андый чакларым да еш була,
Тик ишеттем исә моңлы бер җыр,
Күзләремә гөрләп яшь тула.

Милләтемне яклап, динем хаклап,
Усаллашкан чак та еш була —
Бөек халкым өчен горурлансам,
Күзләремә кабат яшь тула.

Чит җирләрдә сагыш басып китсә
(Ничек кенә чыда-чыдама),
Сагынуларым эчтән ташып чыгып,
Күзләр янә яшькә чылана.

Урамнарда ач балалар күреп,
Түрәләрне «өткән» чак була,
Шушы сабыйларның күзләреннән
Минем күзләргә дә яшь тула.

Ахмаклардан нахак сүз ишетсәм,
Ярсып киткән чаклар да була,
Җайлап кына әйткән җылы сүздән
Күзләремә никтер яшь тула.

Хәсрәтләрдән уелып төшкәннәргә
Ярдәмләшкән чаклар еш була,
Куанычын күрсәм мин аларның,
Шатлыгымнан күзгә яшь тула.

Гомер буе шулай җанда йөртәм
Яңгыр белән елгыр яшенне...
Күңелләрем тулып ташкан чакта
Тыя алмыйм икән яшемне.

*2002*

# Ары табан...

Урап-бурап килгән бураннарга
Кереп киткән идем син юкта,
Чак төртелми калдым буран аша
Томрап торган ике зур утка.

Өнсез калдым, йөрәк кысып куйды —
Ни көтәргә кыргый җанвардан?
Әзерләндем зиһенемне җыеп,
Бирешмәскә, тәндә җан барда.

Басып торам суларга да куркып,
Баткан аякны да алмыйча,
Үзен яуга чакыру күрмәсен дип,
Күзләренә күзем салмыйча.

«Бу баланың авыр күрәчәге,
Газаплары алда», — диептер,
Тими үтеп китте ут күз бүре,
Бәлки, якташлыкны белептер?!

Ышанмыйча борылып карап тордым
Ач бүренең китеп баруын,
Шулкадәр дә мәрхәмәтле җанга
Булды минем тәүге таруым.

Ары табан юллар күп кисеште
Төрле «җанвар», төрле җан белән,
Сеңде шулчак: әдәп, мәрхәмәтлек
Керә икән бары кан белән.

Тешләр кайрап йөрүчене күрдем —
Ул тешләре төште коелып,
Гайбәтчеләр шактый сүз болгатты —
Үзләренә кайтты куерып.

Кайберәүләр, берсен-берсе ашап,
Баштан башка басып үрмәли,
Андыйларга акыл дигәннәре
Анда-санда гына кергәли.

Ә шулай да чын дус күбрәк икән;
Хәсрәтемне белеп — көенә,
Авыр чакта һаман янәшәмдә,
Шатлыгымны күреп — сөенә.

Туганнарым, дуслар шәфкатенә
Тырышам мин җанны төрергә,
Мәңге рәхмәтлемен мин аларга
Һәм тимичә киткән бүрегә!

*1982*

# Матриархат ясап...

Бу дөньясы, ай-һай, нык үзгәрде:
Сылу затлар чыга мәйданга,
Ирләр бил бирәләр хатын-кызга —
Хурланмый да алып салганга.

Билен генә бирсә ярар иде —
Ирлек горурлыгын таптата.
Дөнья — без ул, диеп йөргәннәре
Чеп-чи ялган бүген, сафсата.

Санга сугар ир аз, кайсы хәтта
Аера алмый бауны арканнан,
Кайсы киләп сара, кайсы ахмак,
Кайсы алкаш, кайсы наркоман.

Кайберләре исә гел хатынша —
Бу ни хәлдер, Ходай рәхмәте?
Рәтләләре никтер кырылып бара —
Тигән кебек үләт зәхмәте.

Бөгеп алып көчле егетләрне,
Евнух басты бөтен дөньясын,
Нуры сүнгән, затсыз түбән җаннар
Үзгәрттеләр ирләр кыйбласын.

Үсмерләрне, япь-яшь егетләрне
Шул эз буйлап алып китәләр,
Болар мәңге тездә калсын диеп,
Язмышының колы итәләр.

Түзәбезме? Түзик, түзик әйдә! —
Бетсен ирләр, чумсын шакшыга.
Ник дәшмибез: алдан белә торып
Илтмәслеген моның яхшыга?

Ә бит кызларыбыз киләчәктә
Парын тапмый йөреп тилмерер.
Каберләрдән безне торгызмасмы
Ләгънәт-каргышлардан илерү?

Алар, бәлки, түзмәс мондый хәлгә,
Бүгенге көн калыбын сүтәрләр,
Җир йөзендә матриархат ясап,
Үзләренчә яшәп китәрләр.

*2002*

## Дус булып йөрүчегә

Чагыштырма мине беркем белән,
Үзеңә дә хәтта тиңләмә:
Синең язмыш тик синеке генә,
Мин үз дулкынымда тирбәләм.

Исеңдә тот: чын дус беркайчан да
Көндәш итми дустын, танышын.
Җыруларны син үзеңчә сузсаң,
Минекендә тик үз тавышым.

Мин әйтәсе фикер синдә тумас,
Синеңчәләп мин дә әйтмимен.
Мине беркем кечерәйтә алмас —
Мин һәрвакыт үзем хәтлемен.

*2002*

# Бу ни җанвар?

Чит җирдәге милләттәшләр арасыннан
Кайтып кына кердек бит әле югыйсә.
Бергә йөргән кайбер затлар авызыннан,
Зәһәрләнеп, инде гайбәт җиле исә.

Хәйран вә вәйраннар калып утырамын:
Гаҗәп матур йөреп кайттык бит югыйсә:
Кер эзләүче булгандыр дип һич көтмәдем —
Ник соң болай ямьсез гайбәт җиле исә?

Бер-береңнән көнләшүме, этләшүме —
Артык гамәл кылынмады бит югыйсә.
Нигә ашый кайберләүләр берсен-берсе —
Шул хөсетләр авызыннан ник җил исә?

Кеше чәйнәп һәм каралтып йөри торгач,
Адәми зат йөзен җуяр бу эт җаннар.
Ыслап-шыңшып йөргәннәрен күргән һәркем
Җирәнүбән сорап куяр: бу ни җанвар?

*2002*

# Бүре гел йөреп тора

Әнчекләр өреп торса да,
Бүре гел йөреп тора,
Максатына җитәр өчен
Хәйләсен корып тора.

Юлына төшкән бәндәгә,
Җирәнеп, сикерми дә,
Һау да һау килүчеләргә
Әйләнеп төкерми дә.

Кем ни генә кыланмасын,
Үз дигәненчә эшли,
Тик арттырып җибәргәнне
Умырып алып тешли.

Тел белән җил тарттырганнан
Берәүләр көлеп тора...
Этләр һаман өреп тора,
Ә бүре йөреп тора.

*2002*

# Буш куык

Әчләренә көмеш кунган
Сабакташлар беркөнне
Җыелышып гөрләштеләр,
Туйганчы бер сөйләштеләр,
Искә алып һәркемне.

Аннан сүз китте тормыштан:
Кемнәр ничек яшәгән;
Нинди балалар үстергән
Һәм кем булып эшләгән.

Кемдер туктаусыз зарланды
Бәхетсез язмышына,
Ә берәүләр сагышланып
Үкенде ялгышына.

Нургата гына мактанды:
«Минем тормыш уңайда,
Ни теләсәм, шуны табам —
Йөзәмен балда, майда.

Балалар әйбәт урнашты —
Аларның үз тормышы.
Машина, коттеджлар бирдем,
Һаман торам булышып».

Дәртләнеп китеп, Нургата
Вәгъдәләр бирде өеп:
«Сездәй сабакташларыма
Берни жәл түгел», — диеп.

«Көймәгез комга терәлсә,
Йөрмәгез һич аптырап,
Берне сызгырыгыз гына —
Мин килермен ялтырап».

Мин дә мин дип һаваланды,
Сөйли-сөйли саташты,
Сабакташлар колагына
«Җил өрдереп» маташты.

Ярдәм кулы кирәк булгач,
Юкка чыкты Нургата.
«Кайдан табыйк микән?» — диеп,
Сабакташлар баш вата.

Шылтыратып та карыйлар,
Язып торалар хатны,
Бер җавап юк, әйтерсең лә
Төшеп суларга акты.

Сәркатиптән узалмыйлар:
Эше бик тыгыз икән,
Әле менә яңа гына
Ерак илләргә киткән.

Зур эшләр майтара икән —
Ниндидер алыш-биреш.
Кайчан кайтуы билгесез,
Кайтмавы да бар, имеш.

Менә сиңа кирәк булса,
Менә сиңа Нургата!!!
Шәп сайрады бу «былбыл» дип,
Сабакташлар шакката.

«Нигә исегез китте соң,
Белми идегез мәллә? —
Дип көлде шунда берәве, —
Ул һаман шундый бәндә.

Зурдан кубып вәгъдә бирә,
Кеше көтә сөенеп.
Тик вәгъдә генә үтәлми —
Гозер кала эленеп.

Яшьлектән килгән дуслыкның
Бәясен белгән сирәк.
Аннан ярдәм көтү түгел,
Очрашмау хәерлерәк...»

Бу хәлдән соң Нургатаның
Абруе дөрләп янды —
Сабакташлары алдында
Буш куык булып калды.

*2003*

# Күрик, әйдә, бары яхшылыкны!

*Әлфиягә*

Мәшәкатьләр һаман туып торды,
Борчулары йөрде башлардан.
Әле һаман арынып бетеп булмый
Ашка каршы төшкән ташлардан.

Күңелләрне китеп-китеп алды
Яшәү ямен бозган низаглар.
Бәреп екмаса да, аяк чалды
Әллә кемнәр корган тозаклар.

Барына да түздек, табарбыз дип,
Барыбер табарбыз дип хаклыкны,
Гөнаһлыга күрсәтербез әле
Каралыктан аерып аклыкны.

Үткәннәрне уйлап уфтанмыйк ла —
Киләчәкне күзлик, ахирәт!
Күпме генә иза чиксәк тә без,
Рәхәтем юк, димәскә кирәк.

Күрик, әйдә, бары яхшылыкны,
Көтеп алыйк насыйп бәхетне.
Бәлки, Тәңрем шуңа өстәп бирер
Тиң булырлык затлы сәхипне.[1]

*2002*

---

[1] Сәхип – юлдаш, иптәш, хуҗа.

# Башлык

Башлыктан күп нәрсә юктыр хәзер:
Элегрәк тә алар күп иде,
Әмма бу кадәрле төрле-төрле
Башлыкларны күргән юк иде.

Әнә тора дәрәҗәсез башлык:
Үзе иске, тишек, җитмәсә.
Ярый әле шуграк малай-шалай
«Мә берне» дип тибеп китмәсә.

Мескен башлык күптән төшеп калган
Иелеп йөргән юньсез бер баштан,
Юньлесеннән башлык аерылмый —
Йә чәченнән купмый, йә каштан.

Янәшәсендәге яңа башлык
Үз хуҗасын йөртә кылтайтып,
Ишетеп калыйм диеп, бар гайбәтне,
Колакчынын тота тырпайтып.

Бу башлыкны, бәлки, киләчәктә
Өскәрәк тә элеп куярлар.
Тик, чир китә — гадәт кала, диләр,
Аңардан шул бик тиз туярлар.

Ә монысы менә — әйбәт башлык,
Күрәсезме: нинди күркәм ул,
Чөнки бу дөньяда күпне күргән
Һәм катлаулы юллар үткән ул.

Һәр юлында башлык ут уйнаткан,
Һәр эшенең булган остасы.
Бик күп башка үзе хуҗа булып,
Хөрмәт, рәхмәт җыйган, кыскасы.

Без бит бу башлыкны ничә еллар
Мең рәхмәтләр әйтеп «киябез».
Гомерләре берүк озын булсын
Һәм өр-яңа торсын, диябез.

Миһербанлы башлык искермәс тә,
Тишелмәс тә озак «киюдән»,
Чөнки бит ул гел яңарып тора
Үз хезмәтен, халкын сөюдән.

*2002*

# Туйда котлау

Күңелегезне җилкендергән бу көн
Шатлык рухын сезгә өләшсен,
Йөзегезгә иңгән якты нурдан
Җиһаннарда кояш көнләшсен.

Хәзер инде сезгә парлар итеп —
Исемегезне кушып дәшәбез,
Гомер буе бәхет дәрьясында
Кайгы-хәсрәт күрми яшәгез!

Артык җиңел тормыш кирәк түгел —
Хезмәт белән үтсен көнегез.
Янәшәдә булган чакларда да
Бер-берегезне сагынып йөрегез!

Әби белән бабай булгачтын да
Күзегездә очкын сүнмәсен,
Соң көнгәчә, бер дә сүрелмичә,
Сөю ялкыннары дөрләсен!

*2001*

# Сер бирмәгез!

Ике язмыш бүген бергә китте —
Көннәр ятсын тигез юл булып.
Шушы юлдан, читкә тайпылмыйча,
Бәхет килсен сезгә гел тулып!

Бу юлыгыз чиксез озын булсын,
Кояш аны гел яктыртып торсын.
Җаныгызда былбыл оя корсын —
Мең яшәгез тигез пар булып!

Аяз күктә болыт куера калса
Һәм кинәттән яшен яшьнәп алса,
Сер бирмәгез һич тә җиде ятка,
Михнәтләрне үтеп җилдер атта,
Калыгыз сез бер-берләрен саклап
Яши торган гүзәл яр булып!

*2004*

# Быел җәйдә

2003 елның җәе соң килде. Июнь, июль айлары гел яңгырлы, салкын булды, июль ахырында үтә эсселәр башланды.

Быел җәйдә болыт ишелде,
Әллә күкнең төбе тишелде.
Ишә генә, ишә бу яңгыр,
Игеннәрне кисә бу яңгыр.

Бакчаларда чери бар нәрсә,
Гөрләп үсә бары чүбүлән.
Юллар гына түгел, кырлар да
Инде ташып тулды су белән.

Туктамаса әгәр бу яңгыр,
Уңыш җыялмыйбыз түгелме?
Ямьсез уйлар йөри тирәләп,
Өметсезлек баса күңелне.

Җәй керсә дә, инде ничә ай
Бөртек тулып китә алмады.
Җылы Кояш сорап, Ходайга
Ялвармаган кеше калмады.

Әллә инде газиз бер Ходам
Бу ялваруларны ишетте:
Коеп-коеп яуган яңгырны
Туктатты да җиргә «ут» сипте.

Һәм, ниһаять, кипте бар дөнья:
Урамнары, болын, кырлары.
Җан өрелгән кырлар өстендә
Тургайлар да очынып җырлады.

Анда-санда яуган бозларның
Тимәде күк артык зәхмәте.
Җылы күргәч, боек игеннәр
Котырып уңды, Хода рәхмәте.

Бу көннәрдә халык язмышы
Игенченең алтын кулында.
Югалтмыйча җыйса ашлыкны,
Җырларның матуры язылыр
Уңган хезмәтчәннәр турында.

*2003*

# Татар сые

*(Экспромт)*

Мәскәү өстәлләре сыгылып тора
Казаннардан килгән нигъмәттән,
Талкыш кәләвәләр, чәк-чәк белән
Каклаган каз ята беррәттән.

Күзләр явын алган «Кош сөте»нә
Нинди генә бизәк төшмәгән,
Әкияти бер гүзәллек булып,
Әйтерсең лә килгән төшләрдән.

Татар сыен, үтереп мактый-мактый,
Барча кунак ашый йотлыгып,
Кайберләүләр хәтта рәхмәтләрен
Әйтә алмый тора тотлыгып.

Өстәлләрне бизәп тезелешкән
Тел йотарлык милли сыебыз.
Милләт өчен бер күтәрик әле —
Чәркәләргә шампан коегыз!

*2001*

# Елмаеп яшик

Гомер болай да бик кыска —
Елмаеп яшә җирдә.
Нурлар чәчеп торган йөзгә
Тими иң яман күз дә.

Гел елмайсаң, хәтта эшең
Җайлар килмәгән төшең.
Күңел кайтара елмая,
Көлә белмәгән кеше.

Йә, кем усал сүз әйтала
Елмайган йөзгә карап?
Елмай әйдә, очкынынңны
Төкселәргә дә тарат.

Иң кырыс дигәннәре дә
Каш җыермасын бер дә.
Гомер болай да бик кыска —
Елмаеп яшик җирдә.

*2003*

# Ярый әле судья бар!

*(Уены-чыны бергә)*

Хәйран калам судьяларга —
Ничек чыдыйлар икән,
Эшләр катлаулы булганда,
Кәеф китеп, сабыр бетеп
Чыгымчылыйлар микән?

Мең төрле зар, мең мәгълүмат
Ничек сыя бер башка?
Дөрес карар кылыр өчен
Иң әүвәл үзенә кирәк
Юлында адашмаска.

Әле ул гына да түгел:
Яклаучы сүзе буенча
Акларга кирәк мәлне
Гаепләүче сүз ала да
Куертып куя хәлне.

Суд саен төннәр утырып
Үлчи ул һәр як сүзен:
Бар да көтә гадел хөкем —
Хәтта җинаять кылганы
Гаепле дими үзен.

Менә шушы хәлләрдән соң
Судья әйткән иң соңгы сүз —
Һәммәсе өчен катгый:
Гаеплегә — үз җәзасы,
Гаепсез икән — аклый.

...Көн дә гариза язалар:
Һәрберсендә моң да зар —
Күпме эзләп табылмаган
Гаделлекне кайтарырга
Ярый әле судья бар.

*2001*

## Маймыл елы

*(Экспромт)*

Маймыл елына керəбез —
Тəмам башлар əйлəнгəн.
Авыр хəлдə калмагаек
Күтелмəгəн хəллəрдəн.

Маймылның холык-фигыле
Керəле дə чыгалы,
Уйлый белмəгəн башыннан
Рəтле нəрсə чыгармы?

Шуңа сак булыйк, кардəшлəр,
Əзер булыйк барсына.
Көч һəм гыйлем җыеп барыйк
Яңа елның каршына.

Килергə мөмкин бу маймыл
Төрле зəхмəте белəн.
Һəммəсен җиңеп үтəрбез
Ходай рəхмəте белəн.

*2003*

# Керфегем дә селкенми

Яхшыны чүпкә чыгарып,
Нигә гайбәт сатасың,
Белмисеңме син аларның
Әйләнепләр кайтасын?

Гаеп эзләп, пычрак атып,
Җиңалмагач һичкемне,
Бу — нечкә җан, бирешер дип,
Инде миңа күчтеңме?

Ялгыштың, — көнче сүзеңнән
Керфегем дә селкенми,
Чөнки ул миңа ябышмый,
Абруйны да төшерми.

Явыз хисләргә бирешеп,
Сүзеңне тәмсезләмә,
Көнләшеп көеп йөрүдән
Йөзеңне ямьсезләмә.

Битеңдәге җыерчыклар
Бары шул хөсетлектән.
Һуштан язар дәрәҗәдә
Көнләшеп йөрмә бүтән.

*2002*

# Тагын кая киттең син, Рәсәй?

*(Россия телевидениесеннән бер тапшыру карагач)*

Әле кайчан гына гөрләп торган
Төбәкләрдә берни калмаган.
Түнеп йөри бар да, һаман саен
Өмет итеп нидер Алладан.

Эшләү теләге юк яшьләрендә:
Үтерү, талау — бөтен кәсебе,
Хөрәсәннәр кавеме тамыр җәя,
Бетеп бара Журбин нәселе.

Җимерелеп беткән авыллары,
Исерек халык — кая карама,
Болай барса һаман Рәсәй җире
Әйләнәчәк шыксыз далага.

Кыйшаеплар беткән өйләренең
Җилкапкасы калган тараеп,
Утсыз тәрәзләре аждаһадай
Ыржаеплар тора караеп.

Берәү гармун тарта юл читендә,
Тәгәрәшеп ага күз яше.
Битендәге буразналар буйлап —
Күптән узып киткән үз яшен.

Үзе генә түгел, үкси-үкси
Елый хәтта аның гармуны,
Ыңгырашып чыга бөтен көе, —
Кара сөрем күмгән бар моңын.

Ялкаулыкка кереп баткан Рәсәй —
Ил таркалыр диеп уйламый.
Үз халкына хәтта шәфкате юк —
Йә бетереп бара, йә яный.

Бу гамәлләр аңа күпләп өя
Көчнең бары ямьсез карасын,
Белми микән: узган гасырларга
Каргыш алып кереп каласын?

И Ходаем, нәрсә карыйсың син, —
Әллә сиңа болай кызыкмы?..
Тагын кая таба киттең, Рәсәй,
Таптый-таптый чиктәш сызыкны?

*2002*

# Бөгеп булмас бөек татарны

*Бөтендөнья татар конгрессының*
*III корылтае ачылган көннәрдә*

Кыйбласында янә җыелышты
Дөнья буйлап киткән татарым,
Катгый сүзен ярып әйтер өчен
Коткысына каршы ятларның.

Кайберәүләр көтәләрдер, бәлки,
Кемнеңдер үз халкын сатарын,
Исәп тотмасыннар: беркайчан да
Бүлгәләнмәс минем татарым.

Үз тамырын үзе һич корытмас —
Сөендермәс барыбер ятларны.
Уттан алып, суга салсалар да
Бөгеп булмас бөек татарны.

*2002*

# Сау булыгыз!*

*(Җыр)*

Безне бергә җыйган бу көн
Бәйрәм рухын өләште,
Йөзләрдәге якты нурдан
Хәтта кояш көнләште.

Кушымта:
Сау булыгыз, йөрәкләрне
Төрсен күңел җылыбыз,
Мәңге истәлеккә калсын
Моңнар тулы җырыбыз!

Хисләр дәрьясына чумдык,
Дулкынына күмелдек,
Йолдыз булып балкыдык та
Гөлләр булып сибелдек.

Кушымта.

Рәхмәт яусын барчагызга,
Безне көтеп йөргәнсез,
Эшем кала, димәгәнсез,
Якын итеп килгәнсез.

Кушымта.

Инде хушлашырга вакыт, —
Бәгырьләрдә — сагышлар,
Тагын күрешербез әле,
Язган булса язмышлар.

Кушымта.

*2001*

* Риф Гатауллин музыкасы.



# Багышлаулар

## III

*«Ашыкма, көт, эш күп», – диеп,*
*Каршына йөгереп чыксам да,*
*Туктатып торып булмады*
*Бу гомер агышларын.*

*Җанымда йөргән һәр җыргә,*
*Күңелгә кергән һәркемгә,*
*Мәңге истә калсын диеп,*
*Мин шигырь багышладым.*

# Исхакый*

*(Җыр)*

Халкын сөю хисе Исхакыйга
Килгәндер җир, туган тел аша.
Язмышы да аның, төрле яклап,
Халкы язмышына тоташа.

Кушымта:
Юлларына киртә корсалар да,
Барыбер кайтты Гаяз Исхакый.
«Милләт» дигән тирән ярасыннан
Әле дә булса сыкрап моң саркый.

Милләтемнең азатлыгы өчен,
Тел сафлыгы өчен җан атты.
Гаделлекне даулап йөргән чакта
Йөрәк-бәгырьләрен канатты.

Кушымта.

Көрәшләргә, давылларга керде
Яулар өчен бәйсез дәүләтен.
Чит туфрактан рухы күтәрелеп,
Көтә аның килер сәгатен.
Көтә һаман килер сәгатен.

Кушымта.

*2003*

---

* Луиза Батыр-Болгари музыкасы.

# Клеопатра

*(Экспромт)*

*Юбилее уңаеннан якташым һәм замандашым Дания Салих кызы Дәүләтшинага*

Утыртыйм да вакыт арбасына
Алып китим Лаеш ягына.
Яңартып ал кайбер мизгелләрне —
Бер кайтарыйм «егет» чагыңа.

Чистай, Тигәнәле, Әләскиләр[1]
Торып торсын бүген бер читтә.
Аларга да чират җитәр, бәлки,
Насыйп булып, башка бер кичтә.

Барып килик әле Лаештагы
Гомер эзең калган төшләргә.
Чөнки Лаеш зур трамплин булды
Казаннарга килеп төшәргә.

Бу төбәкне хәйран нык күтәрдең,
Аның белән син дә «зур» үстең.
Тик аякка аны бастырганчы,
Лаеш шулпаларын күп эчтең.

Чиксез абруеңны гомерең буе
Син расладың авыр эш белән.
Юл уңайдан бала табуларың
Алар янда бары төш кенә.

Яшьтән ныгып калган беләкләргә
Эшли-эшли егәр, көч тулды.
Ә шулай да арып, хәлдән таеп
Кайткан чакларың да еш булды.

---

[1] Дания Салих кызының тормышына бәйле урыннар. Ә л ә с к и — Алексеевскины җирле халык шулай йөртә.

Акыл, буй-сын, сәләт һәм зирәклек
Иңдерелгән сиңа күкләрдән.
Кайда гына йөрмә, бу сыйфатлар
Өстен куйды сине күпләрдән.

Хөсетләргә гаҗәп уңганлыгың
Сары майлар булып ятмады.
Ә берәве хәтта ачу белән,
Клеопатра диеп атады.

Ялгышмады: син һәр биләмәңдә
Хуҗабикә булып сөйләштең,
Гомерең буе тормыш матурлыгы,
Иминлеге өчен көрәштең.

Тимер, корыч, дисәләр дә сине —
Күңелләрең тулы нечкә хис.
Бөтерелеп йөргән оныкларың
Синең назга күмелеп үсә ич.

Йөрмәдең син җиңел юлны сайлап
Һәм килмәдең бары әзергә.
Уйлап баксаң, син бит «настоящий»
Патшабикә әле хәзер дә,
Клеопатра әле хәзер дә.

*2004*

# Канәтем

*Якташым Хәсән ага Туфанга*

Күренекле якташларга баймын,
Шул байлыгым бирә горурлык,
Хәсән Туфан дигәннәре хәтта
Үзе генә дә меңгә торырлык.

Хәсрәт-газап тулы шигырьләре
Яралагач күңелем канатын,
Әйткән иде: «Нечкә хисләреңне
Җәрәхәттән сакла, канәтем.

Күңел ярасыннан көнен-төнен
Саркып торса эчкә үз каның,
Дошман сине кыеп кына алыр,
Аңа булышыр кайбер дусларың.

Шуңа күрә дөньяларың онытып
Җебеп йөрмә, канәт, көчле бул,
Кыз-катын бит әле назы белән
Алыпка тиң, лачын төсле ул».

Киңәшләрен тотып Туфан картның
Ерып барам гомер сукмагын,
Аның язмышыннан гыйбрәт алып
Күтәрәмен язмыш тукмавын.

Ул өйрәтте мине югалмаска,
Дуфан* булып дулап исәргә...
Хәсән ага, диеп дәште татар,
Әзи, диде сөеп мишәрләр.

*1998*

---

* Д у ф а н *(мишәрчә)* — давыл, зилзилә.

## Фәтанәт кыйссасы

Бәхетемнән, кадерлемнән
Кара сугыш аерды,
Берегеп үскән пар канатны
Төрле якка каерды.

Котырып искән зәһәр җилләр
Чәчләремне таратты,
Аерылышу мизгелләре
Бәгырьләрне канатты.

Югыйсә бит яңа гына
Аклы иде күлмәгем,
Егерме дүрт тулар-тулмас
Тол каласым белмәдем.

Уңган, чибәр хатын диеп,
Соратмаган калмады,
Тик берсе дә әрнүләргә
Дәва була алмады.

Йөрәк ярасына салдым
Хәбибуллам рәсемен.
Һичберкайчан сынатмаган
Шаһвәлиләр нәселе.

Сәйфиханымны үстердем
Сыңар канатым белән,
Әле дә ярый бер Ходаем
Түзем, сабырлык биргән.

Гомер үтте, күңел көтте
Сөйгән ярны сугыштан.
Йөзе үзгәргән булса да,
Таныр идем сулыштан.

Тәрәз буендагы талга
Былбыл кунмаган икән,
Тигезлектә картаерга
Насыйп булмаган икән.

Тормышымда зур терәгем —
Улым да оныкларым,
Дуслар белән туганнар да
Беркайчан онытмады.

Дөнья куып сизми калдым —
Җиттем мөхтәрәм яшькә,
Хәсрәттән түгел, шатлыктан
Күзем чылана яшькә.

Кемгә барсам да урыным
Булды табын түрендә,
Гомер буе зурладыгыз,
Олылыйсыз бүген дә.

Рәхмәтем зур һәммәгезгә,
Сау-сәламәт яшәгез,
Әманәт шул: һәрбер эштә
Яшен булып яшьнәгез!

*2001*

## Син яшьлектән әле китмәгән

*С.Н-кә*

Алтмышыма кердем инде, димә,
Син яшьлектән әле китмәгән,
Үтеп барган еллар йөзләреңә
Тирән буразналар сипмәгән.

Буй-сының да артык үзгәрмәгән,
Күзләреңдә шул ук очкыннар.
Табигатең синең һаман да яшь,
Әйтерсең лә синдә тылсым бар.

Җиңел тормыш белән яшәмәдең,
Хәсрәте дә булды, сагыш та.
Тезләндерер кебек тоелса да,
Җиңә белдең син бу алышта.

Сабыр гына атлап килеп кердең
Алтмыштагы алтын көзеңә.
Саулык, бәхет янәшәңдә булып,
Җитсәң иде олуг йөзеңә.

*2001*

# Килеп чыгарсың күк тоела

*С.Н-кә*

Күп ел элек, утерүчене эзләп,
«Бергә уттек» байтак сызаны.
Ун корбанның берсе ярдәмендә
Әгерҗедә тоттык без аны.

Мәскәү Зөфәр әсәрендә сине
Сөйләттем мин ана телендә.
Шул чакта ук, гел үз кеше булып,
Урын алдың күңел түрендә.

Повесть, хикәяләр хәйләкәр шул,
Кызыктырып мине алдады.
Аннан китте Закон, Кодекслар,
Регламентлары да калмады.

Бергәләшеп язган бу хезмәтләр
Бер якынлык сузды күңелгә.
Һичбернәрсә шушы якынлыкны
Өзмәс кебек иде гомер дә.

Өзә икән, сорап тормый икән,
Әҗәл дигән шыксыз бер кортка.
Гомерең белән бергә барысын да
Алып китте менә төп йортка.

Шул йортыңның мәрмәр түбәсенә
Инде шаулап яфрак коела.
Җаным кабул итми син юклыкны:
Әле һаман
Баскычлардан йөгереп үткән саен,
Нурың бөркеп, минем алларыма
Килеп чыгарсың күк тоела.

*2004*

# Галәмнәргә барып тоташкан

*(Экспромт)*

*Юбилее уңаеннан Илһам Шакировка*

Хәйран калып тыңлыйм җырлавыңны —
Егет чак әйтерсең үтмәгән.
Шулкадәр моң кайдан килә, дисәм,
Килә икән Тәңре-Күкләрдән.

Бер җырчы да әле синең яшьтә
Җырлый алмый шулай тоташтан,
Чөнки синең аһәң, синең тавыш
Галәмнәргә барып тоташкан.

Синең моңны күмеп китәрдәе
Юк бит һаман татар илендә.
Шул моң белән бергә данлы исмең
Мәңге яшәр халкың телендә!

*2005*

## Сәйдәш моңнары

Кабат җыйды безне Кызыл Байрак —
Кунакларны хәйран күп дәшкән,
Ният изге: безгә тагын бер кат
Моң иңдерү Салих Сәйдәштән.

Тыңлыйк, әйдә, мәшһүр Сәйдәшевне,
Җаныбызны моңга күмгәнче,
Бу моңнарны сердәш иткән бит ул
Иҗатында янып үлгәнче.

Көтмәгәндә язмыш бөтереп алып,
Дөньялары киткәч тараеп,
Югалтулар, хыянәтләр хәтта
Почмак саен торган караеп.

Бәлки әле шулар көч биргәндер
Язар өчен даһи әсәрләр,
Мин ышанам: алар дәверләрдә
Башкаларны узып яшәрләр.

Халык бәгыреннән төшкәнгәдер,
Мәңгелеккә китте юллары...
Үзәкләрне өзеп һаман яңгырый
Сәйдәш җыры, Сәйдәш моңнары!

*2001*

# Соңгысыдыр диеп белмәдем

(Яратканы авызыннан)

*Артистка Фирдәвес*
*Хәйруллинаның якты истәлегенә*

Гомер буе сине якын күреп,
Мин бер фәрештәгә тиңләдем.
Кичә генә «Хуш!» дип китүеңне
Соңгысыдыр диеп белмәдем.

Хәбәр алгач, очып барып җиттем,
Күреп калыйм диеп йөзеңне.
Ник шулкадәр иртә булды соң бу? —
Башлап кына калдың көзеңне.

Төн карасы кебек күзләреңне
Керфекләрең инде ачмады.
Сиңа кагылып киткән кулым буйлап
Назларым да кереп качмады.

Беләсеңме: мин бит көне-төне
Эзләреңә басып йөримен.
Бер елмаеп, алларыма йөгереп
Чыксаң иде диеп телимен.

Әле кичә генә көлә-көлә
Кайтып киттең бит син югыйсә.
Ә бүгеннән сине суырып алган
Кабер өсләреңдә гөл үсә.

Тыя алмыйм, тыя алмыйм яшьне —
Уйларымнан калам чарасыз.
Йөзләремә ятты буразналар —
Сагынуым чиксез, чамасыз...

Тәүге тапкыр күргән көннән сине
Мин бер фәрештәгә тиңләдем.
Кичә генә «Хуш!» дип китүеңне
Соңгысыдыр диеп белмәдем.

*2003*

# Диләрә

*(Экспромт)*

Бүгенниләр сөйли микән —
Йөрәкне тыңлыйм әле:
Иң өлгер кыз Диләрәгә
Мәдхия җырлыйм әле.

Ашханә яктырып китә,
Диләрә килеп керсә,
Һәрберсенең күңеле була,
Елмаеп сәлам бирсә.

«Ни ашыйсыз? — ди ул безгә, —
Кисәк итме, котлетмы?»
Кай арада куеп чыга
Өчпочмакны, компотны?

Аның өлгерлеген күреп,
Барыбыз да шакката.
Ә бер егет, сокланудан,
Җайлап кына сүз ката:

«Диләрәкәй, миңа карап,
Бер генә сүз әйт инде,
Шушы уңганлыгың белән
Үтерәсең бит инде!»

«Ашаганда сөйләшмәгез —
Калырсыз Диләрәсез.
Кемне дә булса аерсам,
Үзегез үпкәләрсез.

Сез миңа барыгыз да бер —
Һәммәгезне яратам,
Исән генә булсыннар дип,
Бу ашларны таратам...»

Күз генә тимәсен диеп
Күзәтәбез сөенеп,
Бездән соң өстәл өстендә
Таулар кала өелеп.

Икенче ашка килгәндә,
Бар да чиста, юылган,
Төрледән-төрле ризыклар
Янә тезеп куелган.

Күңеле төшенкеләрне
Җай таба көлдерергә.
Һәрбересе чират тора
Рәхмәтен белдерергә...

Ниләр әйтә микән диеп,
Йөрәгемне тыңладым,
Уңган Диләрә турында
Бу җыруны җырладым.

*«Ливадия» шифанәсе*

*2000*

# Кайтам әле, кайтам Сабаларга*

*(Җыр)*

Сабаларга искән йомшак җилләр,
Сагыну җырым алып китегез,
Озын юлда аны югалтмыйча,
Әнием урамына илтегез!

Кушымта:
Шул урамда йөргән эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар,
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын итеп әйтер сүзләрем бар.

Бала чакның иркә күз яшьләре
Тулган саен шунда тамгандыр.
Бәлки, шуңадыр да бу гүзәл як
Күңелемә уелып калгандыр.

Кушымта:
Саба юлларында эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар,
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын күреп әйтер сүзләрем бар.

Җилләреңә кушып җырлар юллыйм
Сине сагынып, Саба яклары,
Рәнҗемә син миңа, күпме көтеп
Кайтмады дип, тагын кайтмады.

Кушымта:
Саба урамында эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар,
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын күреп әйтер сүзләрем бар.

*2001*

---

* Фәрит Хатыйпов музыкасы.

# Чакмагыш*

*(Җыр)*

Күәш буе яшел хәтфә,
Шул хәтфәдә — Чакмагыш,
Ямансулап куйдым исә,
Җанымны күмә сагыш.

Кушымта:
Туган ягым Чакмагыш —
Син бит күңел ярасы,
Әллә читләрдә янасы,
Әллә синдә каласы?!

Яшел болыннарда калды
Балачак уеннары,
Бишек җырларына иңеп,
Моң салды уеллары.

Кушымта:
Кайтып күрми баса алмыйм
Йөрәгемнең сызлавын,
Синдә икмәк кенә түгел,
Уңа егет-кызларың.

Кара алтын, урман, таулар
Данлый туган ягымны,
Аның хәтта бураннары,
Җилләре дә ягымлы.

Кушымта:
Чакмагыш, син күңелемдә
Йолдыз булып янасың,
Үзең салган моңнан туган
Җырларымда каласың.

*2001*

---

* Зөлфия Шакирова музыкасы.

# Мәскәүләргә барган идем әле*

*(Җыр)*

Мәскәүләргә барган идем әле —
Милләттәшләр дәште кунакка,
Һичбернәрсә киртә түгел икән
Юлың ятса әгәр шул якка.

Кушымта:
Бу якларда халкым горурлыгын,
Көчле рухын ныграк тойдым мин,
Тынгы белмәс газиз кардәшләргә
Күңелемдә һәйкәл койдым мин.

Мәскәүләрдә хөрмәт күрдем әле —
Һәркайда да зурлап йөрттеләр,
Йөрәк кайнарлыгын өстәп биреп,
Мәңге сүрелмәслек иттеләр.

Кушымта.

Кардәшләрем кунак итте әле —
Күңелләрем тулды мөлдерәп.
Беркайчан да хәтер җуймас өчен,
Аралашып яшәү бик кирәк.

Кушымта:
Мәскәүләрдә халкым горурлыгын,
Көчле рухын ныграк тойдым мин,
Тынгы белмәс газиз кардәшләргә
Күңелемдә һәйкәл койдым мин.

*2001*

---

* Харис Ибраһимов музыкасы.

# Килеп чыктым Нурлат якларына

*(Мәктәпләрдә укучылар белән очрашулардан соң)*

Килеп чыктым Нурлат якларына —
Фәрештәләр хәбәр җиткерде.
Май кояшы кебек якты йөзләр
Магнитларсыз тартып китерде.

Мине көткәннәрнең эзенә басып,
Юлларыннан үттем Нурлатның.
Тамырында татар каны аккан,
Рухыма тиң күпме җан таптым.

Мәктәпләрнең гаҗәп чисталыгы,
Белемлеге һәрбер баланың
Шатландырды нечкә күңелемне —
Мин аларга өмет багладым.

Халкыбызның киләчәген күрдем
Чаткы сибеп торган күзләрдә,
Туган җирен нык ярату тойдым
Дулкын ярып чыккан сүзләрдә.

Шушы буын алып китсә әгәр
Милли рухны килер көннәргә,
Тырыш халкы өчен зур горурлык
Сеңеп калыр иде меңнәргә.

Мәгърурлыкны милли байрак итеп,
Киләчәккә алар атласын
Һәм сакласын явыз ниятләрдән
Үз халкының бәхет капкасын.

*2004*

# Нурлатым*

*(Җыр)*

Юксынудан күңел тулган беркөн
Җаным тарткан якка юл ятты.
Хатирәләр буйлап, уйлар уйлап,
Кайтып барам сагынып Нурлатны.

К у ш ы м т а:
Тирә-күршеләрне сокландырып,
Гүзәл шәһәр булдың, Нурлатым.
Безне йөрткән һәрбер сукмагыңа
Һәрчак балкып торган нур яптың.

Шуңа күрә бүген гаҗәп якты
Юллар гына түгел, җаннар да.
Халкың куйган тырыш хезмәт аша
Даның китте әллә кайларга.

К у ш ы м т а.

Бәйгеләрдә очкан аргамаклар —
Горурлыгы Нурлат җиренең.
Син бит әле тарихларда калган
Бер канаты Болгар иленең.

К у ш ы м т а.

Юксынудан күңел тулган беркөн
Җаным тарткан якка юл ятты.
Хатирәләр буйлап, уйлар уйлап,
Кайтып киләм сагынып Нурлатны.

К у ш ы м т а:
Бар халкыңны чиксез сокландырып,
Гүзәл шәһәр булдың, Нурлатым.
Без йөрисе барлык урамнарга
Балкып торган якты нур яптың.

*2004*

---

* Габдерәзак Мингалиев музыкасы.

# Яшьлегем сукмаклары*

*(Җыр)*

Сызылып аткан алсу таң нурлары
Иңнәремнән сөеп үстерде.
Чишмәләрнең балдан татлы суы
Янып яшәр өчен көч бирде.

К у ш ы м т а:
Сагындырды Апаз[1] яклары —
Юлга дәште сагыну-сагышым.
Яшьлек эзе калган сукмаклардан
Йөгерә-йөгерә кайтып барышым.

Читтә йөргән газиз балаларың
Моңнарыңны алып киттеләр.
Шул моңнарга күчкән исемеңне
Мәңге онытылмаслык иттеләр.

К у ш ы м т а.

Чишмә буендагы бөдрә талга
Бала чагым калды бәйләнеп.
Шул елларга үтеп булмасмы дип,
Җәйләр саен кайтам әйләнеп.

К у ш ы м т а.

*2004*

---

* Габдерәзак Мингалиев музыкасы.
[1] Арча районындагы авыл исеме.

# Казан турында ода*

Кылычлардан кыелса да,
Горур халкым тез чүкмәде.
Күтәрелде, үргә менде —
Якты киләчәген күрде.

Имин тормыш алып килсен
Аткан һәр таң, һәр көнебез.
Милли рухта сугарылып
Ачылсын туган телебез.

Гасырлардан гасырларга
Кыйбла булдың һәр татарга.
Йолдыз кебек балкып яндың,
Йөрәкләргә нурлар салдың.

К у ш ы м т а:
Шәһри Казан — горур калам,
Синнән һәрчак илһам алам.
Бары синдә безнең күңел —
Арижлардан син ким түгел.
Яңгырап торсын изге азан —
Күкрәп яшә, шәһри Казан!

Дан-шөһрәтне һәм михнәтне
Дәверләргә үреп бардың.
Милләт горурлыгы булып,
Тарихларга кереп калдың.

К у ш ы м т а:
Шәһри Казан — горур калам,
Синнән һәрчак илһам алам.
Бары синдә безнең күңел —
Парижлардан син ким түгел.
Яңгырап торсын изге азан —
Күкрәп яшә, шәһри Казан!

* Адел Нуриәхмәтов музыкасы.

Син бүген дә изге кыйбла
Дөньядагы һәр татарга.
Ярдәм ит килер көндә дә
Милләтнең рухын сакларга.

К у ш ы м т а:
Шәһри Казан — горур калам,
Синнән һәрчак илһам алам.
Бары синдә безнең күңел —
Парижлардан син ким түгел.
Яңгырап торсын изге азан —
Күкрәп яшә, шәһри Казан!

*2001*

# Борынгыдан килә Казаным!

*Казанның 1000 еллыгына*

Гөлбакчага күмеп урамнарын,
Көн-сәгатьләп үсә таш кала.
Татар йөрәгендә кайнап торган
Шәһри Казан дигән баш кала.

Мең елларга киткән тарихыннан —
Борынгыдан килә Казаным,
Тирән эзен салып катламнарга
Ябырылган бәла-казаның.

Зур яуларга каршы чыкты Казан —
Тузгып калды ханнар тәхете.
Бүген исә яраларга дәва
Колшәрифнең изге мәчете.

Бөеклеген раслый ак каламның
Үзәгендә торган Ак Кирмән.
Бар дөньяга танытып мең яшьлеген,
Алтын тамга килде хак җирдән.

Җиһаннарга ашкан кодрәте бар,
Шөһрәте бар мәгърур Казанның.
Дәверләрдән күчкән милли рухы
Хезмәтендә чагыла татарның,
Хөрмәтендә чагыла татарның.

*2005*

# Ташлап китмә, Сөембикәм!

*Казанның 1000 еллыгына*

Казансуда дулкын ярып,
Ерак илгә көймә китә.
Шул көймәдә угылы белән
Әсирлектә Сөембикә.

Кушымта:
Йөрәгендә ут янса да,
Күз яшьләре инде кипкән.
Сафагәрәй рухы шулчак
Ялварадыр кебек күктән:
«Ташлап китмә, Сөембикәм!

Дәүләтеңдә татар ханы
Тәхет тотмас инде бүтән:
Бәйсезлеге китә илнең
Синең белән, Сөембикәм.

Кушымта.

Зар елашып озатып калган
Казан халкы шәфкать көтә.
Син аларга соңгы тапкыр
Борылып кара, Сөембикә.
Чит-ятларга бирәсез, дип,
Рәнҗеп китмә, Сөембикә!»

Кушымта:
Йөрәгендә ут янса да,
Күз яшьләре инде кипкән.
Сафагәрәй рухы шулчак
Ялварадыр кебек күктән:
«Ташлап китмә, Сөембикәм!»

*2005*



# Хисләр дәрьясында

## IV

*Йөрәгемнән ургып чыккан хисләр*
*Әйләнделәр инде дәрьяга.*
*Тик бу дәрья тирән кергән саен,*
*Чумган саен өсти бер яра.*

# Бәхет көттем мин

Мәңге арымамын төсле иде,
Әллә нәрсә шунда — арытты:
Әллә ялгыз дөнья куганга мы,
Әллә инде көтеп зарыктым.

Менә килер, менә килер диеп,
Таңнар саен бәхет көттем мин,
Тик һаман да авырлыктан торган
Гомер йомгагымны сүттем мин.

Шул йомгакта кайчак күренеп китә
Сөенечләр тулы көннәр дә.
Бәхет кенә никтер читтә йөри,
Шатлык өстәп әллә кемнәргә.

Сыйпап кына үтсәм дә бит юкса,
Чәчкәләрен ата гөлләрем...
Бәхетемне зарыгып көтә-көтә,
Узып бара дәртле көннәрем.

*2004*

# Хатларыңны укып чыктым...*

Хисең ташып, сөеп язган хатларыңны
Үбә-үбә укып чыктым төн утырып,
Бәхетленең бәхетлесе булган чаклар
Искә төште күзләремә яшь тутырып.

Бу хатларның һәрбер юлы затлы алтын,
Һәр ноктасы дөрләп торган сүнмәс ялкын,
Алар аша ни йөрәккә, ни үзәккә,
Күпме генә тырышсаң да, үтми салкын.

Һәр сүзеңдә назларыңны кабат тойдым,
Ул назларны йөрәгемә салып куйдым,
Мәхәббәтең дәрьясында йөзә-йөзә,
Хәтта вакыт исәбен дә тәмам җуйдым.

Мин ишеттем синең иркә сүзләреңне,
Күрдем җылы бөркеп торган күзләреңне,
Күз алдыма китерделәр ачык итеп
Миңа гына балкып торган йөзләреңне.

И бу хатлар! Күңелемне кузгаттылар,
Сагыш салып, бәгыремне сызлаттылар,
Сүрелмәгән хисләремә ялкын өстәп,
Җаннарыма тагы да көчле ут яктылар.

Йөгереп кереп иңәр булдым кочагыңа,
Әйтерсең лә кабат кайттым яшь чагыма,
Синле булган ул вакытның һәр минуты
Әле дә булса минем уйларда чагыла.

---

* Наил Мортазин музыкасы.

Сөйдем, сөйдең, әле һаман сөеләмен,
Гомернең тиз үтүенә көенәмен,
Кешеләрнең күбесенә бирелмәгән
Олуг хис иясемен дип сөенәмен...

Үлеп сагыну ташып торган хатларыңны
Сыйпый-сыйпый укып чыктым төн утырып,
Дөньяны бер итеп йөргән гүзәл чаклар
Искә төште күзләремә моң тутырып.

*2002*

# Төшкән иде синең яктылык

Тормышымнан көеп йөргән чакта,
Синең сөюеңә тап булып,
Миңа көчеп барган күңел җырың
Минем аша сибә яктылык.

Икәү бергә сәфәр чыккан юлда
Бер нәрсә дә безгә чик түгел,
Арттан өреп калган этләре дә
Хәзер инде безгә чит түгел.

Хәтта карурманнар киртә түгел —
Күз йомганчы чыгып җитәбез,
Тау-ташларны сукмак итеп тезеп,
Диңгезләрне атлап үтәбез...

Үз юлымны тапмый йөргән чакта,
Синең эзләреңә тап булып,
Кыю киттем, чөнки бу эзләргә
Төшкән иде синең яктылык.

*2003*

# Сине сагынып үтә гомерем

Бердәнберем, назлы гөлем дигән
Бер син генә түгел-түгелен,
Тик нигәдер бергә булганда да
Сине сагынып үтә гомерем.

Дөньяларны онытып сөям дигән
Бер син генә түгел-түгелен,
Тик син генә бәхет бирдең миңа —
Һаман синдә бөтен күңелем.

Тормышыңда терәк булыйм дигән
Бер син генә түгел түгелен,
Ник соң һаман сине юксындыра,
Сине генә эзли күңелем,
Сине сагынып үтә гомерем.

*2001*

# Әллә нигә җаным сызлана

*(Җыр)*

Әллә нигә йокы керми бүген —
Сәбәпләр дә моңа юк сыман,
Төнгә карап, таңнар аттырамын —
Әллә инде сине юксынам.

Кушымта:
Җылы иңнәреңдә
Сабый кебек изрәп
Йоклап китәр идем иртәләп,
Йөрәк тибүләрең,
Назлап үбүләрең
Тибрәтерләр иде иркәләп.

Никтер миңа йокы керми бүген —
Әллә кайда йөри уйларым,
Сиңа саулык сорап ялварамын,
Бер Ходама сузып кулларым.

Кушымта.

Авыр уйдан тизрәк арыныр өчен,
Алсу таңга таба кузгалам...
Әллә нигә йокы керми бүген,
Әллә нигә җаным сызлана.

Кушымта.

*2001*

# Гомерлек ярым*

*(Җыр)*

Язлар яме алып керде безне
Тормыш дигән серле дөньяга...
Үтә еллар, бергә уза юллар —
Хисләребез һаман өр-яңа.

К у ш ы м т а:
Синең якты йөзең,
Әйткән татлы сүзең
Сагышларны һәрчак тарата,
Сөюеңне һаман
Күзләреңнән табам —
Яратам, яратам, өзелеп яратам.
Сөюеңне һаман
Сүзләреңнән табам —
Яратам сине, һаман яратам.

Алтын таулар миңа кирәк түгел,
Син бит минем иң зур байлыгым.
Бары синең белән йолдызларга менәм,
Башкаларның белмим барлыгын.

К у ш ы м т а.

Кайда йөреп, ниләр эшләсәң дә,
Синең өчен янып-көярмен.
Гомер бетеп, соңгы минутта да
Сине һаман өзелеп сөярмен.

К у ш ы м т а.

*2001*

---

* Луиза Батыр-Болгари музыкасы.

# Оныттырасың килмәсә...

Сиңа дигән матур хисем
Әле һаман тирәндә.
Миннән суынмасын дисәң,
Гел бөтерел тирәмдә.

Көненә берничә тапкыр
Телефоннан шалтырат.
Ачуланмас микән диеп
Йөри күрмә аптырап.

Миңа рәхәт булып китә
Ишеткәч тавышыңны,
Иркәләп әйткән сүзләрең
Басадыр сагышымны.

Оныттырасың килмәсә,
Ян-тирәмдә ешрак йөр,
Күңелем түренә үтеп,
Назларыңа ныграк төр.

*2002*

# Тыңла йөрәк тибешен*

*(Җыр)*

Сагындым, үлеп сагындым,
Диясем килә сиңа,
Сөю тулы назларымны
Бирәсем килә сиңа.

Кушымта:
Ышанмасаң, тыңла минә
Йөрәгемнең тибешен,
Син генә, дип, яннарыңа
Очып кайтып килешем.

Минутына мең мәртәбә
Күрәсем килә сине,
Ялкын тулы хисләремә
Төрәсем килә сине.

Кушымта.

Керфек очларыңа кадәр
Сөеп үбәр идем мин,
Әле дә син бар, ялгызлыкта
Сулып үләр идем мин.

Кушымта.

*2001*

---

* Габдерәзак Мингалиев музыкасы.

## Булдым инде таңда бер Чулпан

Таң аттырдым зарыгып, телемнән
Әйтеләсе сүзләрем тамды.
Төн буена бөтен галәмнән
Сине эзләп күзләрем талды.

Кушымта:
Ничә еллар әрнидер бу җан,
Булдым инде таңда бер Чулпан.
Миңа кушылып сыкрый бар Җиһан,
Ничә еллар әрнидер бу җан.

Өзгәләнгән күңел тулышты,
Сагышыма хисләр булышты,
Уйлар сиңа юл алу белән,
Күз яшьләре каплый сулышны.

Кушымта.

Таң аттырдым — керфек чыланган,
Әйткән сүзем барып җитмәде.
Инде телдән алып ташладым,
Ә йөрәктән барыбер китмәдең.

Кушымта.

*2003*

# Гөлләр бакчасында

Беркөн чыксам гөлләр бакчасына,
Каршы алды берәү елмаеп.
(Җәннәт агачыдай төз буй-сыны,
Тирә-юне тора нурланып.)

Миңа никтер шундый якын итеп,
Яратып һәм сөеп карады,
Дулкынланып төшкән чәчләремне
Керфекләре белән тарады.

Моны күреп кинәт каушап калдым,
Кояш кебек янды йөзләрем.
Күрсәтмәскә теләп бу халәтне,
Китәр өчен сәбәп эзләдем.

Эзләдем, тик борылып киталмадым —
Күтәрелеп янә күз аттым,
Күз аттым да күңел дәрьясының
Дулкыннарын кабат кузгаттым.

*2002*

# Куймас микән богаулап?

Хәбәр салды: тиз очрашыйк —
Акылдан язып бетәм,
Ташкын хисләремне, зинһар,
Кире какма син бүтән.

Килде, күрдем, хәлен белдем —
Саргайган сагышлардан,
Талкынган йөз, буй-сыннары
Ким түгел камышлардан.

Мөлдерәгән ике күлнең
Су эчендә «таллары»...
Үлеп яраткан бу җанны
Кире бора алмадым.

«Таллар» чыгын эчәр өчен,
Былбыл булып кундым мин,
Алтын балыкка әйләнеп,
Күлләренә чумдым мин.

Чумдым, йөздем, килеп чыктым
Мәхәббәт урләренә,
Шул урләрдән бер сикердем
Йөрәге түрләренә.

Кайнар хисләр, утлы сулыш
Җаннарымны эретте,
Шул мизгелдә ике йөрәк
Бер-беренә беректе.

Инде хәзер бер уй йөри,
Башкаемны бораулап:
Сөю чылбырлары белән
Куймас микән богаулап?

*2001*

# Йолдыз булдың гомер күгемдә

Безнең җаннар аерылгысыз, ахры —
Күңелемә бигрәк якынсың,
Син бит әле йөрәгемә утлар
Өстәп торган сүнмәс ялкынсың.

Ничә тапкыр, хәсрәтемнән шашып,
Сиңа килдем табыш-киңәшкә,
Авырсынып борып чыгармадың,
Каралмадың мине күргәч тә.

Гомер буе киңәшләрең белән
Күтәрештең авыр йөгемне,
Җылы сүзең нур өстәде миңа
Каплаганда болыт күгемне.

Шул көчле нур кара болытларны
Еракларга куып таратты,
Дөньясыннан туйган чакларымда
Яшәр өчен өмет уятты.

Мәңге рәхмәтлемен барысы өчен,
Ярдәмеңне тоям бүген дә,
Якты маяк булдың юлларымда,
Йолдыз булдың гомер күгемдә.

*2001*

# Борчылма син

Тормыш бигрәк сикәлтәле, дисең,
Сикәлтәсезләр дә табыла,
Әмма кайчак хәтта тигез юлдан
Барганнар да бик еш абына.

Таяныр көч торса янәшәңдә,
Сикәлтәләр киртә булалмый,
Михнәте дә сизелмичә кала —
Рухын сүндермәгән югалмый.

Борчылма син, каршылыклар күп, дип,
Китә тора алар барыбер,
Кадерен белер өчен киләчәкнең
Үткәнеңә кара тагы бер.

*2001*

# Чыкты да алларыма...

*(Шаян җыр)*

Чыкты да алларыма ла
Тукталды җаннарымда,
Былбыл кош булып сайрады
Күңелем талларында.

Иңнәремә саклык белән
Кагылды да үз итте,
Күңелең түрендә йөрт дип,
Назына төреп китте.

Ян-тирәмә тезеп куйды
Керфекләрен ук итеп,
Яуларга килгән һәр затны
Торсын, диеп, юк итеп.

Уй салды ла башларыма,
Җаннарыма — вәсвәсә;
Ярый ла сөю-назларын
Мең тарафка чәчмәсә?!

*2002*

# Бөдрә сирень

Син җырладың миңа:
— Гөлбакчамда үсә бөдрә сирень,
Хуш исләргә төрә һәр җирне.
Нигә икән, нигә бу кадәрле
Баш югалтып сөям мин сине?

Гөлбакчама ямь өстәгән сирень,
Җан сөйгәнем, син күк тоела.
Түзалмаслык авыр минутымда
Киләмен дә аңа сыенам.

Бөдрәләнгән сирень чәчкәләре
Иртә таңнан чиксез моң сала.
Бары сине өзелеп сагынуым
Мәңге үлмәс җыр булып кала.

Гөлбакчамда үсә бөдрә сирень —
Шау чәчәктә тора җәйләрен.
Хисләремне раслап, көн дә сиңа
Бүләк итәм сирень бәйләмен.

*1965*

# Багышлау-нәсыйхәт

*Зур ихтирам белән күңелемдә йөрткән берәүгә*

Бу дөньяга килгәнсең син күп яшәргә,
Тирә-юньгә йөзләреңнән нур чәчәргә,
Индерергә зирәк аклыңны яшьләргә,
Әйләнеп йә аксакалга, йә чәчәнгә.

* * *

Эшләрең гел җайга торса,
Дөньяң шатлык белән тулса,
Тирә-юнең балкыш булса —
Сөю килгән булыр сиңа.

Шул бәхетне тота белсәң,
Гыйшык утын йота белсәң,
Борчуларны җиңә йөрсәң —
Җан фәрештәң куныр сиңа.

* * *

Тормышыңны гелән чагыштырып,
Сүз ясата күрмә көндәштән,
Язмышыңнан разый булмасаң да,
Башкаларныкыннан көнләшмә.

Борчу-хәсрәт мәңгелеккә килми —
Китә бит ул өмет калдырып,
Бер кердеме өмет — бар эшеңә
Тора һаман җиңү яудырып.

* * *

Булды, җитте, тәмам ардым,
Дәрманым юк, димә син.
Сагышыңны күреп, беркем,
Беткән бит бу, димәсен.

Бирешергә һич уйлама —
Әле бит егет чагың.
Шайтанга иман укытып,
Гөрләтеп яшә тагын.

* * *

Син — сөю төзеп калдырган
Олы тормыш сарае.
Тормасын ул беркайчан да
Караеп һәм тараеп.

Булсын анда варисларның
Шатлыклы тавышы да,
Алардан тынып торганда,
Наз тулы кавышу да.

* * *

Күп сүз — чүп сүз, ди бит безнең халык —
Җанны тыңлар вакыт бит инде,
Йөрәк аша сулап, акыл белән уйлап,
Күңел ярларыңа җит инде.

Сиңа кирәк хәзер сердәш җанның
Сихәт биргән тавышын ишетү,
Язмышыңның авыр минутларын
Күптән күргән моңсу төш итү.

Серле тавыш бер ярдәмче булыр
Калган юлны матур үтәргә,
Әрнүләрдән торган көннәреңне
Сабыр сандыкларына итәргә.

*2002*

## Соңарып килгән сөю

### Әйттең беркөн:

— Гомерем буе
Дөньям онытып
Гашыйк булудан
Куркып йөрдем,
Чөнки җиһаннарга сыймас
Әрнүләрне,
Сызлауларны
Мин аңардан гына
Күрдем.
Күңелемнең сыктауларын
Күтәралмам
Төсле иде,
Шуңа күрә бар сөюем,
Тау-ташларны
Күчермичә,
Сабыр гына агып барган
Хисле иде.
Ә беркөнне,
Сине күргәч
(Аллаһы Тәгалә биргәч),
Барыбер дә
Сукты сәгать,
Көтмәгәндә
Картлыгымда
Өермәсе белән килде
Зур мәхәббәт.
Күмде мине
Үтә авыр сагышларга,
Газапларга
(Нигә кирәк булды икән,
Гомерләр узып барганда,
Утка салып
Азапларга?)

Дөньяларда
Мондый сөю буладыр дип
Белми идем,
Яшьлектә дә
Болай итеп,
Шашар дәрәҗәгә җитеп,
Хыялланып
Йөрми идем.
Көне-төне сине уйлап,
Диванага
Сабыштым мин.
Сөюне соңга калдырып,
Бераз гына
Ялгыштым мин.
Һичберниндиге кысаларга,
Калыпларга
Сыймыйм хәзер,
Хәтта синең
Эзләреңне,
Моң тутырук
Күзләреңне
Үбеп үләргә дә әзер.
Бер генә көн дә
Сагынмый
Һәм исемеңә «кагылмый»
Тора алмыйм.
Сине һәрчак
Истә йөрткән,
Хыялым назына керткән
Ни гакылым,
Ни уй талмый.
Миңа гына елмайгандай,
Нур бөркелгән

Рәсемеңне
Бик кадерләп
Алып куйдым
Өстәлемә.
Ниһаять,
Үзе күрсен дип,
Озакка сузмый
Керсен дип
Бу хәлемә.
Юлда гына түгел икән,
Дөрләп янган
Сөюдә дә —
Гүр газабы.
Тик белмимен:
Бу газапның,
Талкып торган
Миң азапның
Ни белән бетәр
Азагы?!

*2003*

## Диде берәү:

— Түзалмадым, әйе, түзалмадым,
Үз-үземне күпме тыйсам да,
Синең кебек чәчкәдәй бер затка
Тиң түгеллегемне тойсам да,
Җыйдым әле синең номерыңны,
Гаеп итмә берүк, хурлама.
Үз яшемне мин болай да беләм,
Артык олы, диеп «зурлама».

Чәчрәп китеп ихлас көлүеңне,
Нәфис тавышыңны сагындым.
Күрмәсәм дә, хет ишетим диеп,
Телефонга килеп кагылдым.

Беләсеңме: шушы яшемдә мин
Йолдызларны күзлим төннәрен.
Яктылары шактый икән, әмма
Синнән яктырагын күрмәдем.

Зинһар өчен, көлә күрмә миннән,
Шул яшендә шашкан бу, димә,
Сиңа бәйле тормышны үз иткән
Йөрәк-бәгырьгә дә син тимә.

Үз-үзеңне онытып хыяллану
Минем яшьтә, бәлки, сәердер.
Акыл хисне йөгәнләгәндә дә
Сөя алырмын күк әле бер.

Тыңлыйм әле матур тавышыңны —
Шифасына җанны күмелдер.
Ходай сиңа биргән шундый бер көч —
Сине сөйми мөмкин түгелдер.

Әмма бу көчеңнән куркам да мин:
Бер сөйдерер, ике көйдерер,
Күмерләнеп беткән йөрәк белән
Йөрелмәсме кеше көлдереп.

Шуңа көннәр, төннәр буе йөрим
Шылтырата алмый, тыелып.
Бер киләмен катгый карар белән,
Тагын китәм тәмам коелып.

Бераз яшьрәк чагым булса әгәр,
Йөрмәс идем болай тилмереп:
Очып кына килеп җитәр идем,
Канатымда алып китәр идем,
Фәкать үземнеке итәр идем
Ризалыгың алып иң элек.
Аерылмас гүзәл парлар булып,
Бер-беребезнең йөрәгенә тулып,
Сөю дәрьясында йөзеп-чумып,
Яшәр идек назга күмелеп...
Бу уйлар шул тик бер хыял гына,
Син барлыкны бары тоям гына,
Кагылалмыйм хәтта кулыңа —
Бир сабырлык, Ходам, колыңа!

*2003*

## Диденң шунда:

— Өеңә генә түгел, күңелеңә дә
Тимер ишек куйсаң иде син,
Башкаларның юлын кистерерлек
Таш коймалар койсаң иде син.

Миннән бүтән һичкем күз салмасын,
Күңелеңә дә үтеп кермәсен,
Минем сабырлыкны сыный-сыный,
Ян-тирәңдә бөтерелмәсен.

Күрәм бит мин: пәйда булдың исә
(Әйтерсең лә ябь-яшь кыз бала),
Җыелыша бар да синең янга —
Минем шуңа җаным сызлана.

Кемдер кулларыңны сыйпап үтә,
Кемдер китә кагылып чәчеңә.
Сере гади: чөнки синең йөздән
Көлтә-көлтә ак нур чәчелә.

Шуңа да мин синең игътибарың
Миңа калмас диеп куркамын...
Тик үземә җәрәхәтләр өстәр
Газаплардан торган укларым.

*2003*

## Әйттең шулчак:

— Мин Ходайга рәхмәтлемен
Сине күрсәткән өчен,
Янәшә атлап барырга
Бәлки җитмәс тә көчем.

Артык җитезләнмәсәм дә,
Егәрсездән түгелмен,
Син йөрисе сукмакларга
Сагыш булып түгелдем.

Синең кебекләр бит, җаным,
Бар җиһанда санаулы,
Сине күргән көннән бирле
Йөрәкләрем ямаулы.

Акыллым, син фәрештәдер —
Башымны җуймас идем,
Канатым пары булалсаң,
Яратып туймас идем.

Салып куйдым инде сине
Йөрәгем кесәсенә.
Мин ризамын хәтта җанны
Телемләп кисәсеңә.

Берүк исән-сау була күр
(Бу минем чиксез теләк)!
Бу дөньяда син бар икән,
Мин дә яшимен, димәк.

*2003*

## Әйттең шунда:

— Бик эчендә тотар түземем юк,
Күңелемдәгеен мирга таратам.
Аеруча синнән яшереп булмый —
Үз-үземне белми яратам.

Гаҗәп түгел: мин дә җан иясе,
Миндә дә бит йөрәк, хисләр бар.
Яшеңә күрә — ашың, дип, миндәйгә
Бүлеп биргән дөнья миңа тар.

Киңәйтәсем килә офыкларны,
Озайтасым килә гомерне,
Назлыйсым һәм назланасым килә —
Исәр хисләр били күңелне.

Яшәтәсең мине, яшәртәсең,
Бу яшәрү — үзе могҗиза.
Тик калыпка мәгънә килмәгәнгә,
Йә елый җан, йә бер җыр суза.

Исәрләнәм бугай инде һаман
Бер син генә телем төшемдә.
Бу хәлемә чик куй булдыралсаң,
Авырлыгын уйлап төшен дә.

Йә ачылып китсен күк капусы,
Йә бәрелим барып кыяга.
Чәлпәрәмә килсен бөтенесе,
Кабул итмәс булсаң дөньяңа.

*2003*

## Дигән идең:

— Әй-й-й! Яшьрәк чагым булсамы?
Яшьрәк чагым булса әгәр, сине
Гел йөгертер идем артымнан.
Бик беләсең килсә, әле һаман
Араланып булмый, һич тынгы юк
Хатыннарның яше-картыннан.

Хут бирмәде бер дә кыз-кыркын да:
Бер артыма төште, бер алга.
Һичберкайчан ялгыз тилмермәдем —
Үз кирәгем булды гел янда.

Олыгаеп барам инде хәзер,
Инде үлеп гашыйк булынмас.
Дөньяларны онытып йөреп булмас,
Гөнаһлар да инде кылынмас.

Шулай дигән булам гына инде —
Күземне бит синнән алалмыйм.
Күпме тыелырга тырышсам да,
Сиңа игътибарсыз калалмыйм.

Котырынма, диеп, күпме әйтәм
Һаман ярсып торган йөрәккә.
Бар син менә, гамьсез булып кара,
Сандугачлар торгач тирәктә.

Менә сиңа күз төште бит әле —
Елмаюың бигрәк үтерә.
Сөю-назлар тулы бәгыремне
Телем-телем итеп киптерә.

Әй-й-й! Яшьрәк чагым булсамы?
Яшьрәк чагым булса әгәр, сине
Урлап кына китәр идем мин.
Зарларыңа, ай-ваеңа куймый,
Үземнеке итәр идем мин.

*2004*

## Диден миңа:

— Бу арада күренмичә торсам,
Син югалтма мине, тәтием.
Саулык бераз аяк чалды әле —
Көн эчендә үлеп терелгәнне
Ничек кенә итеп әйтием?

Ничек дисәм, куркытмамын икән? —
Синең җан бит нечкә кыллардан:
Өзеп куймыйм тагын дип борчылам,
Йә китәрбез аеры юллардан.

Син, тәтием, миңа үпкәләмә,
Хәбәр бирми торсам берара.
Мин булырмын сүзләр йөрмәс җирдә —
Мине дә бер сагынып кара.

Сагынуыңның магнитка тиң көче
Алып кайтыр мине яшәүгә.
Сөендерер назы белән, ә бит
Соңгы гомердә дә мәгънә бер үк —
Сөеп һәм сөелеп яшәүдә.

*2003*

## Әйтте берәү:

— Сүнгән шәмнәр кабат янсын әле,
Җанга үткән бозлар эресен,
Синнән бүтән миңа үз булалмый —
Китмә, зинһар, җансыз түгелсең.

Менә иңнәр, бусы — кайнар йөрәк —
Терәк булсын диеп бирәмен.
Бәхет китерердәй киләчәкне
Синең белән генә күрәмен.

Араланыйм шыксыз көннәремнән,
Ялгызлыкта син дә интекмә,
Таптап үтмә өмет-хисләремне,
Ризалыгың бирче, тилмертмә!

Нинди генә көчле булсам да мин,
Таянырга кирәк синең кул...
Галәм тиңләшерлек парым бул син,
Җиһан көнләшерлек ярым бул!

*1996*

## Әйттең көеп:

— Мәңге яшибез күк йөрмә икән —
Бер секундта китеп барасың,
Шуңа күрә бу дөньяда тизрәк
Алу кирәк алып каласын.

Өлгерермен диеп йөрмә икән,
Көтмә икән җайның килүен,
Үзең җаен табып яшә икән,
Күрмим дисәң язмыш көлүен.

Иртә әле, диеп йөргән идем —
Соң икән лә, артык соң икән.
Тик якадан үлем тоткач кына
Югалтканны барлыйсың икән?

Мин бирешмәм, диеп йөрмә икән —
Бирештерә икән бер тузгач.
Уйны хәтта борып булмый икән,
Булмый икән гомер бер узгач.

Һич көтмисең өзелеп сөйгәннең дә
Беркөн ташлап китеп барасын.
Дәрт-дәрманлы чакта белмисең шул
Үкенечкәниләр каласын.

Гел яшәрсең кебек йөрмә икән —
Көтмәгәндә китеп барасың,
Шуңа күрә бу дөньядан күбрәк
Алу кирәк алып каласын.

*2003*

# Пәри кызы

Дигән идең:
«Беркөн очрап, гүзәл пәри кызы
Күз карашы белән яндырды,
Кара урман кебек чәчләренә
Адаштырып кертеп калдырды.

Шул мизгелдән башлап, бу гүзәлне
Сагынудан йөзем карала,
Аны күрми торган һәр минутым
Уклар булып җанга кадала.

Мең газапка хәтта мин түзәрмен,
Мәхәббәтен көтеп гүзәлнең,
Тик барыбер аны парым итеп,
Бәхет дәрьясында йөзәрмен».

*2002*

## Бер карасаң...

Беркөн әйттең:
«Күзләремә бер карасаң,
Ут-ялкынны күрер идең.
Бөтен дөньям дөрләп яна —
Хәлләремә керер идең.

Йөзләремә бер карасаң,
Сагышымны күрер идең.
Сулып саргаймасын, дисәң,
Яннарыма килер идең.

Йөрәгемә бер карасаң,
Җәрәхәтләр күрер идең.
Аларга дәва син генә —
Назларыңа төрер идең.

Бер тутырып кара инде —
Хәлләремне белер идең.
Сөюемне тибәрмәсәң,
Куенында эрер идем».

*2002*

# Хатларыңда яздың миңа...

— Син булмагач, киптем:
гел сагышта бит мин.
Җаным сыкравыннан
ничек качып китим?
Синнән башка хәзер
читлектәге кош мин —
Бәргәләнәм һаман —
ничек сабыр итим?
Нишләттең син мине?
Исәрләнәм бит мин.
Төнем көнгә күчте —
ничек дөнья көтим?
Кояш йөзләреңне
күрми күрәм бит мин.
Атлап йөрүең хәтта
күз алдымнан китми.
Кодрәтлем син минем,
Алиһәгә тиңем,
Тотма ут эчендә —
көеп үләм бит мин.
Гомер йомгагымны
тагын күпме сүтим? —
Кайт, дип әйтүеңне
мең ел көтәм бит мин.
Саклыйм назларымны,
башкаларга түкмим.
Кушыйк язмышларны —
синсез бетәм бит мин!

*2003*

## Керфек өсләреңдә чатыр корып...

Әйттең миңа:
«Сине күргән көннән, и гүзәл яр,
Сихерләнгән утта янамын,
Керфек өсләреңдә чатыр корып,
Күз нурыңнан сихәт аламын.

Йөрәк ярсуларын басар өчен,
Йөргән эзләреңә кагылам,
Алларымда торган һәрнәрсәдә
Синең нурың булып чагылам.

Диңгез кебек төпсез күзләреңә
Ушым китеп төшеп чумамын,
Чумамын да, көчкә аңга килеп,
Тыным бетеп килеп чыгамын.

Упкыныңда батып калмас өчен,
Кубар өчен диңгез төбеннән,
Мин бит сине бөтен тормышымның
Ханбикәсе итәм бүгеннән».

*2002*

# Янында кеше булса соң...

Нигә куркасың?
Янында кеше булса соң.
Мин бит сиңа
Шигырь генә
Укыйм дигән идем.
Мәхәббәт шигыре.
Сине һаман да
Яратуым турында.
Хисләремнең
Барысы үз урынында.
Күңелең күтәрелеп,
Җаның тынычлап
Киткән булыр иде.
Йөрәгеңә,
Бөтен тәнеңә
Сихәт тулыр иде.
Нигә куркасың?
Янында кеше булса соң.
Ул да тыңласын.
Белмәгәндәй
Кыланып тормасын.
Бөтен җиһан белгәнне,
Бөтен гавам күргәнне
Яшерә алмыйсың.
Ә бит үзең
Миннән башка
Яши дә алмыйсың.
Нигә куркасың?
Янында кеше булса соң...

*2003*

# Яулап алдың бугай

Тукта! Кемнең йомшак тавышы бу? —
Йөгереп килдем шушы тавышка,
Игътибарны алган син икәнсең:
Шундый якын, шундый таныш та.

Телләреңнән бары гөлләр тамды,
Әйтерсең лә назда тирбәлдең.
Сүзең сонда, каерылып китеп,
Гармуныңны сузып җибәрдең.

Күңелләрем тулды шул мизгелдә —
Син һаман да йөрәк ярасы,
Гармуныңа кушылып, синең көйгә
Килде шунда шәрран ярасы:

«Җитте, зинһар, туктат гармуныңны,
Бәгыремә төшеп уйнама.
Онытты да бетте, ятка китте,
Юксынмыйдыр, диеп уйлама.

Тавышыңны ишетеп йөгереп килдем,
Тавышың әллә канга сеңдеме?
«Буең белән түгел, уең белән,
Өең белән түгел, көең белән
Яулап алдың бугай син мине».

*2002*

# Тәгълимнамә

*(Инструкция)*

Әйдә инде, бер очрашыйк, дисең,
Утырыйк, дисең, хет бер сөйләшеп,
Әйтер сүзең бөелеп тора, ахры —
Күрешик соң әйдә, серләшик.

Тик сүзләрең берүк чама белсен —
Йөрәк ярасына кагылма:
Җөйләнеп тә әле өлгермәгән —
Тирәнәюе бар тагын да.

Сөйлә миңа бары матур сүзләр,
Йөрәгемә ятсын май булып,
Күңел җылытырлык фикерләрең
Килеп кенә торсын җай булып.

Ишетәсем килми яман сүзләр,
Ялган сүзне бигрәк сөймимен,
Чөнки үзем бары дөресен генә,
Туры сүзне генә сөйлимен.

Ихлас булсын хәтта күз карашың,
Ясалманы бик тиз тоям мин,
Хәйлә корып, ятьмә тарттырганнан
Авызын ачмас борын туям мин.

Тик шул чакта сине мин үз итеп,
Игътибарым биреп тыңлармын,
Йөзең генә түгел, җаныңның да
Матурлыгын тоеп зурлармын.

Риза булсаң әгәр бу шартыма,
Әйдә соң, бер утырып сөйләшик,
Бүгенгене матур киләчәккә
Үзгәртерлек итеп серләшик!

*2002*

# Истанбул гөлләре*

*(Җыр)*

Бүләк итеп син китергән гөлләр
Әле һаман балкый вазамда.
Истанбулда тамыр җәйсәләр дә,
Хуш ис бөрки хәзер Казанга.

К у ш ы м т а:
Каршы алды, озатып калды
Истанбул гөлләре.
Гомерлек сагышка салды
Истанбул көннәре.

Әллә инде матур гөлләреңә
Хисеңне дә кушып бирдеңме,
Күзе төшкән саен, түзә алмый,
Мине сагынып куйсын, дидеңме?

К у ш ы м т а.

Керәмен дә гөлләр дөньясына,
Әкияттә сыман йөримен.
Насыйп булып, Истанбулны кабат
Күрсәң иде диеп телимен.

К у ш ы м т а.

*2003*

---

* Габдерәзак Мингалиев музыкасы.

# Бүлмәм саен элдем рәсемеңне

Һәр бүлмәмдә синең фоторәсем —
Узган саен карап үтәмен.
Түзалмасам чиксез сагынуга,
Мин аларны үбеп китәмен.

Шул чагында синең рәсемнәргә
Җан кергәндәй була бер мәлгә.
Кайнар тының миңа күчә сыман,
Ирененә иренем тигәндә.

Үзәкләрем өзелеп төшкән чакта,
Җырларыңны тыңлап юанам.
Мин аларга кушылып китәмен дә
Моңнар дөньясына юл алам.

Сагыш-моңнар талкый күңелемне,
Беләм: син дә мине уйлыйсың.
Өннәреңдә күрә алмасаң да,
Төшләреңдә сөеп туймыйсың...

Бүлмәм саен элдем рәсемеңне,
Чит күзләрдән пәрдә корсын дип.
Рәсмең аша үткән күз нурларым
Кайтыр юлың булып торсын дип.

*2003*

# Тик хатларың никтер тоткарланды

Хатларыңны көтеп тилмерәмен —
Еш язармын, диден: кич-иртә.
Никтер алар килеп җитми һаман —
Көн артыннан тагын көн үтә.

Ярый әле телефоннар эшли —
Тавышыңны ишетәм, син — мине.
Сөйләшкәндә хәтта ятлар белән
Сүзләр сайлыйм бары «син»лене.

Телефоннан нәрсә сөйләшәсең? —
Иркенәйгән чаклар бик сирәк.
Барысын да әйтеп бирер өчен,
Барыбер дә озын хат кирәк.

Тик хатларың никтер тоткарланды —
Адаштылар мәллә юлларда?
Дөньяларны байтак гизәләр шул
Килеп ирешкәнче кулларга.

Тилмерәмен көн дә хатың көтеп,
Еш язармын, диден югыйсә.
Әллә инде вәгъдәң нык булмады —
Сезнең яктан бары җил исә.

*2003*

# Җылы яңгыр булып сибәли

Араларны өзү авыр булыр —
Күңелемә кереп өлгерден.
Ул гынамы?
Борып чыгармасын диеп куркып,
Үзәккәрәк таба йөгерден.

Бәгыренә үтеп керсәм әгәр,
Кире кага алмас, дисеңме?
Ялгышасың:
Җәрәхәттән каннар саркыса да,
Мин йөгәнли алам хисемне.

Киртә булган бар нәрсәне җиңеп,
Тартылса да сиңа хис-күңел,
Тик барыбер
Синең дөньяң бары сиңа гына —
Минем дөньяларга үз түгел.

Шул сәбәпле каршылыклар тезәм
Син киләсе сукмак тирәли.
Ә шулай да,
Тилмерепләр йөргүеңне күреп,
Күңел яшем килер сукмагыңа
Җылы яңгыр булып сибәли.

*2003*

## Нигә кирәк сиңа минем сөю?

Нигә кирәк сиңа минем сөю,
Җитмәгәнме әллә булганы?
Аннан башка әле ян-тирәңдә
Йөрүчеләре бар болганып.

Нигә кирәк сиңа минем сөю,
Бары санга тулсын өченме?
Әллә нигә күрсәтәсең килде
Минем алда шашкын көчеңне.

Синдә әгәр табигый көч булса,
Миндә сөю, назлар көчлерәк,
Салкын карашны да ут итәрлек,
Сүнми торган ялкын төслерәк.

Нигә кирәк сиңа минем сөю?
Болай да күп сине яраткан.
Мин кабынсам, син дә дөрли-дөрли
Янып китәрсең бит кабаттан.
Нигә кирәк сиңа минем сөю?

*2003*

# Әллә яратам инде?

Мин сине галәмнән эзлим,
Яннарымда юк чакта.
Сөйләгән сүзләрем хәтта
Бары тик синең хакта.

Газабым чиксез көчәя,
Озак күрмәсәм әгәр.
Үзәкләрне телеп китә
Сагыну дигән зәһәр.

Булыр идем мин һәрвакыт
Татлы иренең колы.
Иркәләр идем шашынып —
Йөрәк наз белән тулы.

Никтер һаман сагындыра —
Йөзләргә сагыш иңде.
Җаныма урын табалмыйм —
Әллә яратам инде?

*2003*

## Әзлим

Күзләреңне эзлим,
Күзләреңне,
Әйтә алмый калган
Сүзләреңне,
Кулларыңның
Иңнәремә салган
Җылысын.
Уттай өтеп алган
Иреннәрең,
Күз алмамда калган
Шат йөзләрең
Искә төшсә,
Килә җылыйсым.

*2003*

# Куркытма!

Кинәт
Яшен суккан кебек
Булып китте,
Күңелем йомшарды,
Тыным бетте.
Авырый дигән хәбәр
Шулай тәэсир итте.
Барып бәрелер урын
Табалмадым,
Алып киткән чакта
Сине күреп
Калалмадым.
Мин дә кергән булыр идем
Яннарыңа,
Маңгаеңда
Кулым торса,
Хәл дә керер иде
Җаннарыңа.
Бәгырькәем,
Моннан ары
Болай куркытма,
Сиңа борылган зәхмәтнең
Үзен куркыт та
Куып җибәр
Каф тавына,
Иялəндермә
Яныңа.
Берүк
Исән-сау йөр,
Күңелең булсын
Һәрвакыт көр.
Йөзеңдә уйнасын
Нур!
Сәламәт бул!

*2003*

# Яратышу булмаса...

Ярлар парын мәңге тапмас,
Күздә очкын тормаса.
Дөньяның нинди яме бар,
Җанда сөю булмаса?

Җиһаннарга очмый күңел,
Ләззәтләнеп тормаса,
Тик ләззәт тә мәңге түгел,
Газаплары булмаса.

Кайнар мәхәббәт тә сүнә,
Ялкынланып тормаса,
Хөсрәүгә — Ширин, Мәҗнүнгә
Үз Ләйләсе булмаса.

Хәтта язлар дәртләндерми,
Чәчкә атып тормаса.
Яшәү гаме калмас иде,
Яратышу булмаса.

*2003*

## Сискәнеп куйдыңмы?

Син мине тойдыңмы,
Мин сине тойдыммы?
Нәкъ менә шул мәлдә
Ишегем шакыгач,
Сискәнеп куйдым мин.

Күзләрдә — елмаю,
Ишетелми тын алу,
Каушавым сизденме:
Син керден сак кына -
Сарылмый чак торам.

Керфекләр очрашты,
Битебез — битләрдә,
Һәр ике тарафтан
Ягымлы карашлар
Күтәрә күкләргә.

Йөзләрдә — алсу таң,
Күзләрдә — нур-солтан.
Хәл-әхвәл сорашу
Җанланып сүз башлар
Өчен тик бер сылтау.

Син барны тойдыммы,
Мин барны тойдыңмы?
Шул мәлдә китәргә
Дип әмер килгәч тә,
Сискәнеп куйдыңмы?

*2003*

## Нишләрем?

Беләмәче, зинһар, җаннарымны,
Кирәксезгә башны бутама,
Иләнем инде ялгызлыкка,
Юкса кабат уйлар бутала.

Ымсындырма мине назың белән,
Кыннарында торсын укларың,
Ычкыныплар китсәм йөгәнемнән,
Туктый алмам диеп куркамын.

Бәгырьдәге утлы күмерләрне,
Көйдермәсен диеп, көримен,
Күңел карышканга гаҗиз булып,
Урын табалмыйча йөримен.

Тыям-тыям ярсу дулкынымны,
Күмеп китмәсен дип кинәттән,
Ыргылырга торган тулпарымны
Авызлыклап куеп берәттән.

Ни хикмәттер, каршы торган саен
Арта гына бара хисләрем,
Ургып чыгып, давыл-өермәдәй
Кабат бөтереп алса, нишләрем?

*2003*

## Кочагыңа алып сөйсәң...

*(Шаяру)*

Нишләп йөрисең соң әле
Миннән башка чит җирдә,
Үзәге өзеләдер дип
Уйламыйсыңмы бер дә?

Утыр да кит, утыр да кит —
Кеше шулай яшиме?
Сизмәсеннәр дип, көлүгә
Төрәмен күз яшемне.

Сагыну саргайта, диләр,
Саргаймый торыйм әле:
Син кайтканчы, йөрәгемдә
Бер кальга корыйм әле.

Син дә мин генә сыярлык
Матур кальга булыр ул,
Икебезне табыштырып,
Кавыштырып торыр ул.

Китә алмассың син аннан
Берүземне калдырып,
Син кайтуга, бар юлны да
Куярмын мин яндырып...

Юк, болай да булмый икән
Сине бәйләп, богаулап,
Үзәккә кадәр төшәрсең
Күзең белән бораулап.

Аңлыймын инде, аңлыймын —
Син бит укалы түрә,
Һаман йөреп тора торган
Вазыйфаң. Шуңа күрә

Гафу итәрмен, китсәң дә
Дөньяның почмагына,
Тизрәк кайтып алып сөйсәң
Шифалы кочагыңа,
Ут кебек кочагыңа.

*2003*

# Әллә инде чынлап үпкәләдең?

Әллә инде чынлап үпкәләдең?
Үпкәләмә, зинһар, кирәкми.
Сине күрми киту болай да бит
Авырттырып тора йөрәкне.

Сәбәпләрен әүвәл белми торып,
Үпкә белдермәсәң иде син,
Шиккә салып һәрбер адымымны,
Хисем сүндермәсәң иде син.

Мин битараф калыр идем моңа,
Әгәр сине якын итмәсәм
Һәм үзең дә мине сөеп кенә,
Назларыңа төреп йөртмәсәң.

Үпкәләрлек берни юк бит әле,
Бар булганым шуңа раслама,
Сүрелмәсен, дисәң, моннан ары
Белер-белмәс гаеп ташлама.

*2002*

# Хәерле юл!

Хәерле юл сиңа, хәерле юл!
Берүк исән-имин йөреп кайт.
Юлларыңа тезәм догаларым,
Һәрбересен укып йөз мең кат.

Хәерле юл сиңа, хәерле юл!
Кайтыр юлларың да ак булсын.
Йөргән җирләреңдә һәрчак бары
Яхшы кешеләргә тап бул син!

Хәерле юл сиңа, хәерле юл!
Алып кайтсын илткән юлларың.
Сине көтә-көтә талып бетә
Каш өстендә торган кулларым.

Хәерле юл сиңа, хәерле юл!
Ераклардан имин йөреп кайт.
Бөтен эшең гел уң булсын, диеп,
Теләк теләп калам йөз мең кат.

*2003*

# Кемнәр бәйләде?

Бу уйларың кайда йөри микән,
Кышлардамы, әллә җәйдәме?
Сүзләреңә нигә төртеләсең —
Телләреңне кемнәр бәйләде?

Күз ташларга хәтта тилмерәсең,
Керфекләрең әллә бәйдәме?
Очкыннары никтер чәчрәп тормый —
Күзләреңне кемнәр бәйләде?

Тигез җирдә нигә абынасың,
Аяклар да богау-бәйдәме?
Күктән йолдыз җыйган кулларыңны
Каерып куеп кемнәр бәйләде?

Тәнең-жаның тулы җәрәхәттер —
Бөтен җирең бәйдә, богауда.
Тик хисләрең барыбер ташып чыгар,
Сөйгән ярга кучкәч кенә тынар —
Дилбегәсе чөнки Ходайда.

*2002*

# Илгә күрендем инде

Башымны баскан уйлардан
Иелдем, сулдым инде,
Хөсрәүеннән аерылган
Бер Ширин булдым инде.

Канатымның пары сынды —
Япа-ялгызым калдым.
Телеп киселгән йөрәккә
Зур-зур ямаулар салдым.

Ямауларны тегә-тегә,
Канга батты бармаклар.
Алырга килгән җиреннән
Кире китте пар атлар.

Китә алмадым утырып
Бизәкле тарантаска.
Инде ничек кенә итеп
Зиһенне таратмаска?

Хис дәрьясын йөзеп чыктым
Аркылыга, буйга да.
И Ходам, бу газапларны
Кертмә бүтән уйга да...

Ялкынымны дөрләтмәгәч,
Сүндем, сүрелдем инде.
Бәлки, ялгыз яшәргәдер? —
Сөйдем, сөелдем инде.
Хөсрәүнең Ширине булып,
Илгә күрендем инде.

*2003*

# Хәтерлимсең?

Хәтерлимсең: йолдызлы бер кичтә,
Иңне иңгә терәп утырып,
Шигърияттә йөзгән җаныбызны
Чын матурлык белән тутырдык!

Рәхәтләнеп шигырь укыдык без,
Акылыбызны төреп хисләргә.
Катлам-катлам яткан шигъри юллар
Балкып торды төрле төсләрдә.

Үткәнеңне күбрәк белер өчен,
Шул юлларда йөгереп йөрдем мин,
Гел алышта узган елларыңны
Җан сыкравы аша күрдем мин.

Давыллары дулап алган икән,
Күп нәрсәне сытып, туздырып.
Шул давылда имин йөрткән бәгърең
Юл күрсәткән һәрчак күз булып.

Сызлауларың киметим дип, сине
Алып кердем гөлләр багына:
Анда һәркем үткән тормышының
Бары матур чагын сагына...

Хәтерлимсең: уйны уйга теркәп,
Без шигырьләр укып утырдык,
Серләшәсе килгән күңелләрне
Сихри моңнар белән тутырдык?

*2003*

# Юлыңнан минсез китәрсең

Мин курчакларга сине чөйдем,
Сүзеңнән чук сарай өйдем,
Җәүһәргә тиң күреп сөйдем —
Ә син гади таш икәнсең.

Күмдем сине ак бәхеткә,
Утырттым алтын тәхеткә,
Әйләнмәдең тик сәхибкә —
Игелексез зат икәнсең.

Абруеңны таптамадым,
Йөзләреңне тапламадым,
Ә син шуны акламадың —
Ышанычсыз җан икәнсең.

Гомрең үтәр сикереп-атлап,
Бар дөньяңны сагыш каплап,
Тора алмам сине саклап,
Юлыңнан минсез китәрсең.

*1982*

# Бигайбә

Исәп-хисап итеп утырам әле:
Никтер назың учак көйрәтми,
Сөеп әйткән сыман сүзләрең дә
Күңелемә ялкын дөрләтми.

Зиһеннәр дә бик таралып китми
«Гүзәлем син минем» дигәнгә.
Шуңадыр да сине үз дөньяма
Якын җибәрмимдер, бигайбә!

*2002*

## Ни он суы, ни тоз суы...

Сүзең саен мактанасың,
Миңа акча — чүп, дисең,
Ә үзең, кибеткә кергәч,
Һаман тиен чүплисең.

Бәлки, байлыгың да бардыр,
Зурдыр, шәт, исәбе дә,
Әмма син бит минем алда
Бер кыржын кисәге лә.

Бер алдыма, бер артыма
Төшмә сайрап көн саен,
Ни он суы, ни тоз суы
Булмас синнән, дускаем.

*2002*

## Бер канатым сынык икән лә...

*(Җыр)*

Яз сулары китте агызып,
Көннәреңә илтте күзеңнең.
Кояш күрми иртә саргайган
Яфрак кебек миннән өзелдең.

Кушымта:
Мин бит сине һаман сагынам,
Барып күрим диеп талпынам.
Бер канатым сынык икән лә —
Килеп төшәм очтым дигәндә.

Синсез язым инде яз булмас,
Җаннарыма инде наз тулмас,
Җиһан әйләндермәс кулларың
Өзелеп калды килер юлларың.

Кушымта:
Мин һаман да сине сагынам,
Күреп килим диеп талпынам.
Бер канатым сынык икән лә —
Килеп төшәм очтым дигәндә.

*2003*

## Сәрләүхәсез

Күзләремнән минем яз эзләмә —
Син бит минем тиңем түгелсең,
Ярларына сыймый ташкан хисең
Үз тиңеңне табып түгелсен.

Сүзләремнән минем наз эзләмә,
Йә ияртеп алып китәрләр,
Ә аннары, юлдан яздырды дип,
Кардәшләрең мине битәрләр...

* * *

Битәрләсә инде, битәрләр —
Эзлә, әйдә, минем назларымны,
Язларны да эзлә күземнән,
Керсез яратуны нигә әле
Яшерергә кеше күзеннән?!

Тиң түгелне сөю гөнаһмыни? —
Шундый ук саф хисләр ләбаса!
Бәхет бит ул: кеше үз гомерендә
Өзелеп сөйгән ярын табалса.

Көймим әле, хисең нигезсез, дип,
Тормыш үзе аны нигезли,
Ялкын көчле булса, тиңсезне дә
Язмышына куеп тигезли...

* * *

Тигезләвен бераз тигезли,
Тик аерма барыбер чәчрәп тора,
Күзгә керә, менә күр диеп,
Эзсез узмый кеше сүзләре дә,
Кылдан нечкә күңелгә тиеп.

Никадәрле көчле булса да ут,
Еллар үткәч, шактый сүреләә,
Шул чагында ярның тиңсезлеге
Аермачык булып күренә.

Үкенүләр, уфтанулар китә,
Китә шуннан ялган, хыянәт,
Бар нәрсәнең асты өскә килә:
Әйтерсең лә тормыш — кыямәт...

* * *

Яшәү — газап, гомер юлларында
Булса бары кара төн генә...
Һәркайсыбызны да газиз Аллам
Кушсын иде тик үз тиңенә.

*2001*

# Ялвару

И Бер Ходам! Синдә бөтен хикмәт,
Син язганнан беркем узалмый,
Мин тезгәнне насыйп итсәң иде —
Килер көнне шулай күзаллыйм:

Тулы зиһен белән камил акыл
Бир син миңа, Тәңрем, сүнгәнче,
Үзең салган сәләтемне алма,
Тырышлыгым калсын үлгәнче.

Аерма син сөйгән хезмәтемнән,
Адаштыра күрмә юлымнан,
Дошманнардан дусны аера белим,
Үкенмәслек булсын соңыннан.

Изге ниятемдә калдыр мине,
Кертә күрмә шикле сукмакка,
Йөзләрем ак, күңелем пакь булсын,
Ялгыш адымнардан син сакла!

Саулыгымны бир син миңа, Раббым,
Таулар күчерәсем бар әле,
Тирә-юнем бакча булсын өчен,
Гөлләр үстерәсем бар әле.

Балаларым тырыш хезмәт юлын
Алсын иде зур маяк итеп,
Ярдәмеңнән син дә ташлый күрмә,
Сәламәтлек өстә күп итеп.

Бир син тагын миңа тиң булырдай,
Җанны аңлый торган бер кеше,
Ул гына да түгел, тормышымны
Күтәрерлек булсын һәр эше.

Янә килеп, әни, туганнарым
Сау-сәламәт булып яшәсен,
Һәммәсе дә казанышлар белән
Язмышында күкрәп яшьнәсен?

И Бер Ходам! Синдә бөтен хикмәт,
Син язганны беркем сызалмый,
Үз теләгәнемне язсаң иде —
Алдагыны шулай күзаллыйм.

*2002*

# Рәсем

Күптән түгел генәерактагы
Кардәшләрне килеп күрәсем,
Мәскәүләрне гизеп йөргән чакта,
Кулга килеп керде бер рәсем.

Хәтерлисең микән: башкалада
Сабан туе көнне җыелып,
Без сурәткә төштек, ядкәр булып
Калсын диеп мәңге уелып.

Син башыңны миңа таба иеп,
Якынайткан уйлар арасын
(Ышанмасаң сүзем раслыгына
Бу сурәтне килеп карарсың).

Ә мин исә синең иңнәреңә
Сыеныплар бетеп басканмын,
Әйтерсең лә, югалудан куркып,
Кочагыңа кереп качканмын.

Балкып торган йөзләр, нурлы күзләр
Тезелешкән безгә янәшә,
Сүзсез генә рәхәт елмаябыз,
Җаннар гына туймый серләшә.

...Калды, калды мәңге ядкәр булып,
Безне сыендырган бу алан.
Гомерләрнең матур мизгелләрен
Исебезгә төшерер ул һаман.

*2001*

## Гәпләшәсем килә утырып

Кайчакларда синең белән генә
Гәпләшәсем килә утырып,
Чишеләсем килә бары сиңа —
Сер капчыгым күптән тутырык.

Көннәр буе, әле төннәр буе,
Бертуктамый язам, язам мин.
Язып аргач, тәмләп сөйләшергә
Кеше тапмый азапланам мин.

Шуңа күрә сине көтеп алам —
Тел ачыла, кулга ял биреп.
Авырсынмый җавабыңны кайтар,
Минем сорауларга өлгереп.

Хәлләреңне бераз сөйләп җибәр,
Эшләреңдә нинди яңалык?
Мин тыңлармын сине тын да алмый,
Кочагыңда эреп, таралып.

Аптырама: әгәр, әйдә әле,
Бер гәпләшик, дисәм, утырып,
Кочагыңа бөтереп ал да мине,
Күзләремә карап тутырып,
Сөйлә миңа бөтен уйларыңны,
Мин дә сиңа кушылып сөйләрмен,
Ә аннары, тәмам күңелем булып,
Синең көйне генә көйләрмен.

*2002*

## Ярлыкагыз мине!

*(Уены-чыны бергә)*

Өрлек кебек чибәр егетләрне
Сугыштырган чаклар бар иде.
Никтер алар бер сукмактан йөрде,
Әйтерсең лә дөнья тар иде.

Көмеш тамчы шактый җемелдәде
Горур егетләрнең күзендә.
Шул энҗеләр янә ялтырады
Гашыйкларның үпкә сүзендә.

Хәтта дистә елга яшьрәкләр дә
Юлларыма төшеп тилмертте.
Бер җавапсыз калган мәхәббәте
Ушын алып, тәмам тилертте.

Ярлыкагыз мине, әй, егетләр!
Тиң күрмәдең мине, димәгез.
Бәхеткәең шуңа булмады дип,
Йөрәк ярама да тимәгез.

Хәзер инде гомер узып бара,
Үткәннәргә ачу сакламыйк:
Искә төшерергә саф хисләр бар,
Күңел пакьлегенә ак төсләр бар —
Үпкә тотмыйк әле вакланып.
Йөрмик әле хәзер вакланып.
Ярармы?

*2002*

# Сөюне керткән идем

Күңел тәрәзәмә чирткән
Сөюне керткән идем,
Кибә алмыйча тилмерткән
Яшемне сөрткән идем.

Күңелем тирәкләренә
Былбыллар кунган иде.
Бөтен дөньям, дөрли-дөрли,
Ут белән тулган иде.

Чәчкәле җәй уртасында
Кыш килерен көтмәдем.
Син шуңа бирешерсең дип,
Уема да кертмәдем.

Җылытмак булып тын өрдем —
Җаным гына өзелде.
Вакытсыз яуган кар булып
Узып киттең көзеңне...

Күңел тәрәзәмә чирткән
Сөюне керткән идем.
Мәхәббәтемнең соңгысы
Булыр дип көткән идем.

*2003*

# Кышкы озын кара төннәрдә

Кышкы озын кара төннәрдә
Уйлар төшми микән кемнәргә?
Узган гомерен кабаттан күрә,
Яшьлегенә мең кайтып килә,
Тәүге ярлар сөйгән көннәргә
Артык озын кышкы төннәрдә.

Бу тормышта шактый яшәлгән,
Бәлки, арылгандыр яшьнәүдән.
Тик шулай да яшәү кадерле,
Беленмәгән моңа кадәрле.
Барысы уйга өелә бер мәлдә
Кышкы озын кара төннәрдә.

Салкын җилләр хәтер пәрдәсен
Күтәрә дә куя кайчакта.
Елый-елый аннан үтәмен,
Болар бар да минем үткәнем.
Сөйлим аны, сөйлим кемнәргә
Кышкы озын кара төннәрдә?

*2003*

# Үзең тагын килдең төшләргә

И Ходаем, оныталмыйсың, ахры —
Күпме гомер үтте бит инде,
Барган җирләреңдә урын табып,
Тыныч кына миннән кит инде!

Фани дөньялардан бакыена
Киткән чакта инде бик күптән,
Әйткән идең: «Яңа йортка күчәм,
Килә алмам инде мин бүтән».

Сүзләреңдә генә торалмыйсың,
Тотасың да килеп керәсең
Төшләремә, мине яратуың
Һаман кайнар, сүнми, күрәсең.

Кичә тагын йөрдең сабыр гына,
Төсең үзгәрмәгән әллә ни —
Яшь чактагы килеш, ә мин менә
Инде хәйран вакыт дәү әни.

Ниләр бимазалый җаннарыңны,
Ни әйтергә миңа телисең?
Сер ачасы килгән кеше сыман,
Бөтерелеп янда йөрисең.

Әйт тә инде шушы сүзләреңне,
Тынычлыкта калдыр син мине,
Әллә инде синең беркайчан да
Китәсең дә миннән килмиме?

И Ходаем, оныталмыйсың, ахры,
Аерылмыйсың миннән һичләр дә,
Бәхилләшеп киттең бит югыйсә,
Үзең тагын килдең төшләргә.

*2001*

# Әле яңа гына

Әле яңа гына балкып торган
Күзләремә кабат моң төште.
Шушы моңның элеп талкуыннан
Мәңге арына алмамын төсле.

Керфекләрем инде күтәралмый
Өелешеп торган тамчыны.
Тамган берсе, йөзең чагылдырып,
Бәгыремне кисеп камчылый.

Әле яңа гына балкый идем —
Яраларын ачтың йөрәкнең.
Галәмнәргә күчтең, саубуллашмый,
Ядкәр булып калды сурәтең.

*2004*

## Нигә җебеп утырасың әле?

Нигә җебеп утырасың әле,
Күзләреңнән чишмә агызып?
Кем күрмәгән дөнья авырлыгын,
Тилмертмәгән кемне ялгызлык?

Беләм инде, беләм, күреп торам:
Әлегә хәлең түгел яхшыдан.
Баш ярылып күз чыкмаган ласа,
Киләчәкне уйла яхшылап.

Борчуыңны миңа күчермә син,
Үз борчуым үземә җитәрлек:
Тезеп салсаң, озын юллар булып,
Галәмнәргә таба китәрлек.

Мин болай да синең өчен көям,
Телим сиңа бары уңышлар.
Киләчәгең бары синнән тора —
Язмышлардан хәтта узмыш бар.

Болай җебеп утырма син башка,
Үз-үзеңә бир дә боерык,
Эшләреңне әүвәл үзең җайла,
Бар вакытың үтсен эш-гамәлдә,
Утырмаслык булсын боегып.

*2003*

## Хәтерләргә уелып калырлар

Курыктың син минем кайнарлыктан,
«Матур» диеп котың алынды.
«Синдәй белән авырдыр ул», — диден,
Үзең исә һаман сагындың.

Бераз күрми торсаң, шылтыратып,
Тавышымны тыңлап юандың.
Шаярышып сөйләшкән сүзгә дә
Бала-чага кебек куандың.

Колагымда һаман яңгырап тора
Рәхәтләнеп көлгән тавышың,
Һәрбер сүзең серле моңы белән
Күңелемә калды ябышып.

Кәефең киткән чакларыңны күреп,
Борчылуым чыкса йөземә,
«Үтә торган, бар да үтә торган», —
Дия идең, карап күземә.

Артык мәшәкатьле чагыңда да
Каршы алдың йөзең ачылып.
Миңа ышандырган сүзләреңне
Сөйләр идең кайчак ачынып.

Бер сукмактан көн дә йөрсәк тә без,
Эзләр бик еш туры килмәде.
Беркөн очрашуны соңгыдыр дип
Белмәдем лә, син дә белмәдең.

Әллә сизендеңме? Киткән чакта
Кабат-кабат борылып карадың.
Үзең атламагач миңа табан,
Мин дә сиңа каршы бармадым.

Үкенечкә кала икән шулай
Уйлап җиткермәгән адымнар...
Көләч йөзең, тапкыр шаян сүзең
Хәтерләргә уелып калырлар.

*2004*

## Ни мәгънә соң?

Сине яратудан ни мәгънә соң? —
Тиң түгелсең, бигрәк тиң түгел.
Арабызда — шактый еллар, тик син
Башкалардан бер дә ким түгел.

Күзләреңнең утлы очкыннары
Күзләремә салды мең чаткы.
Юлларыма нигә чыккансыңдыр
Сөю көтеп йөргән бер чакны?

Бетмәгән бит җирдә бутәннәр дә,
Бетмәгән лә үзеңә тиң ярлар.
Минем юлга инде озакламый
Акрын-акрын төшәр ак карлар.

Диден миңа: «Җиһаннарны урап
Озак йөрдем сине тапканчы.
Таптым. Сөям. Мәңге сөярмен мин,
Йөрәгемә сулу капканчы.

Шикләреңне, зинһар, белдермә син,
Бу сөюем — соңгы рәхәтем.
Җан канатып эзләп таптым аны,
Юлларыңа мине чыгарганга
Аллаһыма чиксез рәхмәтем».

Кадер-назга төргән көчле хистән
Мәгънә эзләп була димени?
«Парың булыйм! Кума!» — дип торганда,
Нәфрәтләнеп була димени?

*2003*

## Ничә еллар...

Ничә еллар төрле юлдан йөреп
Саргаешып беттек бит инде.
Җайлап кына сукмагыңны борып,
Минем юлларымнан кит инде.

Бер могҗиза булыр, күрешә калсак,
Бер-беребезне танырбыз микән?
Йөрешләрең, карашларың, бәлки,
Шулай уктыр: көн-төн мин көткән.

Инде мин дә олыгаеп барам,
Тик шулай да һаман син белгән.
Бер күрүдә танырсың син мине,
Хәтта чәчемдәге чал белән.

Минем юлга үзең төшалмасаң,
Мине алып кер үз юлыңа.
Хәбәр салсаң, калган гомеремне
Тапшырырмын синең кулыңа.

*2003*

# Хәерлегә булсын!

Ничәнче көн һаман эчем поша
(Хәерлегә булсын, Ходаем!)
Сине җилкендергән уй-хисләрем
Китеп баргангадыр, мөгаен.

Сизеп торам: сүрелүем тойсаң,
Йөрәк җәрәхәтең ачылыр.
Бергә булу өметең кинәт шулай
Киселгәнгә җаның ачыныр.

Челпәрәмә килсә хыялларың,
Ышанычың бетәр сөюгә.
Йөзләреңнең караласын беләм,
Мин суындым сиңа, диюгә.

Эздән йөреп саклыйсың син мине,
Югалтудан куркып, мөгаен...
Инде ничәнче көн эчем поша,
Хәерлеге булсын, Ходаем!

*2003*

# Фарсы белән аралаш

*(Шаяру)*

Үзең килалмасаң әгәр,
Яннарыңа мин барам:
Чакырып тора туктаусыз
«Ман туро д ст медорам!»[1]

Йөрәгемә утлар төште —
Каршы торыр юк чамам.
Синең һәр кич әйткән сүзең:
«Хоби ширин, и ҹонам!»[2]

Йокыны бик китерми шул —
Куа да куа гына,
Башкаемда төрле уйлар
Туа да туа гына.

Күзләрең нур чәчеп тора,
Яннарыңда мин булсам.
Җай чыгуга пышылдыйсың:
«Дашном надех, — мебусам».[3]

«Чи хел ҳастед?»[4] дип сорыйсың,
Хәлләр болай түзәрлек.
Арган чаклар була анысы,
Хәл калмый җеп өзәрлек.

---

[1] Мин сине яратам!
[2] Тыныч йокы, и җаным!
[3] Ачуланма – үбәм.
[4] Хәлләрең (эшләрең) ничек?

Шул мәлдә сиңа дәшәрмен:
«И духтур, инҹо биё!»[1]
Эшләрем күп, армас өчен
Дәрман бир әле миңа.

«Мархамат, мархамат!»[2] диеп,
Килеп җитәрсең, беләм,
Тәсбихыңны тарта-тарта
Нечкә бармагың белән.

Гаҗәеп шәфкатьле бит син —
Булышмаган кешең юк.
Җаның шундый булгангамы,
Бер килмәгән төшең юк.

Ярдәмгә сине дәшкәндә:
«Көттермә, ашык!» — димен.
Синең чиксез рәхмәтеңә:
«Саломат бошед!»[3] — димен.

Ярый, хайр[4], бүгенгә шул,
Хуш омадед[5] иртәгә.
Хафа нашав[6] бу сүзләргә,
Керми калса киртәгә.

*2003*

[1] И табиб, килче бире!
[2] Баш өсте, баш өсте!
[3] Сәламәт бул!
[4] Сау бул.
[5] Рәхим ит.
[6] Үпкәләмә.

## Сөю китермәгән назлар нигә?

*(Фарсыдан)*

Сөю китермәгән назлар миңа нигә?
Шәрабсыз чәркәләр ник кирәк?
Сөеклемнән башка матур яшел болын,
Хуш ис бөркеп торган тын бакча да
Болганчык бер сазлык төслерәк.

Сандугачсыз роза — гөлмени ул? —
Сула, коела, сары төс баса.
Төн белән Күк, Йолдыз иле нигә,
Юлларымны яктыртып һәм балкып,
Яннарымда Аем тормаса?

Иң уңган хатын да берни түгел,
Йөрәгендә сөю булмаса.
Мәхәббәттән башка нинди яшәү ди ул? —
Сөю белән ялкынланган җаның
Ләззәтләрдән иңрәп тормаса?

*2003*

# Аралагыз сез мине

*(Фарсыдан)*

Кирәкмәгән теләкләрдән аралагыз сез мине,
Кимсетеп көттерүләрдән аралагыз сез мине.

Сөям диеп саташудан, хатын-кызның хәйләсеннән,
Буш куыктай вәгъдәсеннән аралагыз сез мине.

Саран ачкан кочагында эрүләрне сагынудан,
Көнләшүләр газабыннан аралагыз сез мине.

Хискә төрмәгән назлардан, санап кына үбүләрдән,
Боздай салкын күрешүдән аралагыз сез мине.

Чынга ашмас төш-йокыңнан уян инде, и җаным
Юкса кирәксез газаптан аралап булмас сине.

*2003*

# Күпме көттем

Күпме көттем килеп керерсең дип,
Ә син әллә вакыт тапмадың,
Әллә инде онытып җибәрдеңме
Кайдалыгын безнең капканың?

Исләреңнән чыгып китте мәллә
Миңа илтә торган сукмаклар,
Шул сукмаклар буйлап сабыйларча
Тотынышып йөргән яшь чаклар?

Онытырлык түгел иде юкса:
Кайнар хисләр, ашкын күңелләр
Күзебездән күзне алдырмады, —
Эзебез саен үсте ак гөлләр...

Күпме көттем! Килеп керерсең дә
Бөтереп алырсың күк тоелды.
Күренмәдең. Бөтен өметләрем
Челпәрәмә килеп коелды.

*2003*

# Син юк инде бүген минем янда

Син юк инде бүген минем янда,
Тоймыйм инде кулың җылысын.
Сагыныплар өлгердемме әллә? —
Бер дә юктан килә елыйсым.

Син юк инде бүген минем янда,
Юлың ерак, кайту тиз булмас.
Син булгандагы күк яна алмам,
Йөземә дә инде нур тулмас.

Син юк бүген, әмма бөтен җирдән
Күңелем белән барыбер эзләрмен.
Берәм-берәм үбеп чыгармын мин
Синнән калган барлык эзләрне.

*2003*

# Китә калсам

*(Җыр)*

Сезне ташлап китәр көн җитеп,
Сәфәр чыксам бакый дөньяга,
Югалттык дип хафаланмагыз —
Рухым калыр сезнең дөньяда.

Кушымта:
Гомерем бетеп, фани дөньядан
Китә калсам, хушыгыз, кызларым!
Бәлки, бүген соңгы көнемдер,
Бәлки, бу сүз соңгы сүземдер.

Китә калсам фани дөньядан,
Бәхил булсагыз ла, дусларым,
Туганнарым һәм сөйгән ярым,
Китә калсам фани дөньядан!

Тәннәремне ялкын-ут алып,
Тирән яралардан сызланып
Китеп барсам, зар-зар елашып
Яшь түкмәгез сабырсызланып.

Кушымта.

Анда кояш инде балкымас,
Йөрәкләрем болай ярсымас.
Онытмыйча минем төсемне,
Сагынырсыз микән сез мине?

Кушымта.

*1998*

# Мин озаттым сине

Мин озаттым сине озын юлга,
Күзләремә кояш төшереп,
Күңелеңә борчу кертмәс өчен,
Үксүемне эчкә яшереп.

«Берүк елый күрмә озатканда,
Юкса юлым уңмас, — диден син, —
Каралмасын күз-яшь белән йөзең,
Якты сибеп торган нурым син».

Шуңа да мин сине озатып калдым,
Үксүемне этеп тирәнгә.
Син киткәч тә өлгерермен, тик шул
Юатучым булмас тирәмдә.

Күзем күлгә әйләнмәсен дисәң,
Озак йөрмә киткән җиреңдә.
Саклыйсың бар мине, үткәрмичә
Яңгырын да, зәһәр җилен дә.
Озак йөрмә киткән җиреңдә.

*2003*

# Кирәгең бетте инде

*(Шаян җыр)*

Ничә ел көттем инде,
Җанымны өттең инде.
Киләм, диден — күренмәдең,
Аңа карап сүрелмәдем.
Таһирын көткән Зөһрә күк,
Саргаеп киптем инде.

Мәгърибләрдән эзләп кайттым,
Мәшрикъка киттем инде.
Йөрим хәзер дөнья буйлап,
Көне-төне сине уйлап.
Бер күрергә тилмерүдән
Ябыгып беттем инде.

Йолдызлардан урап килдем,
Айларга күчтем инде.
Кара чоңгылларга кереп,
Андагы мәхшәрне күреп,
Кирәксез йөргәнне белеп
Кайттым да киттем инде.

Күңел сынды, җаным тынды —
Кирәгең бетте инде.
Киләсе юлыңны үзем
Килмәслек иттем инде.
Бигайбә, көтмәдем түгел,
Ничә ел көттем инде.

*2002*

# Газәлләр

* * *

Язмышым сызган юллардан һаман ялгыз атладым:
Мәңге таяныч булырлык терәгемне тапмадым.

Үтеп бара гомерләрем сәхрәләр, чүлләр аша,
Иреннәр кибеп ярылды — кояш миңа тоташа.

Яндырды да, көйдерде дә шул кояшның нурлары,
Һаман михнәткә чыгарды язмышымның юллары.

Күтәрдем мин ул михнәтне, урталай бөгелсәм дә,
Сиздермәдем башкаларга, сөенсәм, көенсәм дә.

И Гөлчәчкә[1], бу тормышта ничек авыр булмасын,
Ходай күрсәткән сукмактан барыбер тайпылма син!

*2003*

---

[1] Гөлчәчкә — Флёраның татарча мәгънәсе.

* * *

Суга иелгән талларга былбыл килеп кунамы —
Тал былбылсыз, былбыл талсыз бу дөньяда буламы?

Каен белән чагыштырма сылу кызның гәүдәсен —
Төз үскән матур кәүсәнең хәрәкәте буламы?

Зарыгып көтмәсәң, килми очрашуның рәхәте —
Чәчкә аткан роза гөле чәнечкесез буламы?

Сөйгәнем белән аерылу сызлавына түзәмен —
Мәхәббәттә түзми янган берәр гашыйк буламы?

Йөрәгемнең яралары, син карауга, җөй булды —
Сөеп туймаган карашлар бер сихәтсез буламы?

Җимерелгән диварларның шәүләсе төшмәс җиргә —
Күңелдән киткән ярларның шәүләләре буламы?

И Гөлчәчкә, ташкын хистән күңелләрең туламы —
Синең дә челтер чишмәңдә су кипкән чак буламы?

*2003*

* * *

Иреннәрең балдан татлы — мондыйлар сирәк, дидең.
Беркемне дә кагылдырма — үземә кирәк, дидең.

Күзләреңне каймалаган керфегең — тирәк, дидең.
Сыендырма башкаларны — үземә кирәк, дидең.

Күңел дәрьяңда йөзәмен, рәхәттән изрәп, дидең.
Башка беркемне чумдырма — үземә кирәк, дидең.

Тының кайнарлыгы өтә — сызамын көйрәп, дидең.
Сүзең уты дәрман өсти — миңа шул кирәк, дидең.

Синнән иңгән зур ләззәттән каламын иңрәп, дидең.
Сине беркемгә бирмәмен — үземә кирәк, дидең.

Китәсең, җаныңны калдыр — йөрәгем төргәк, дидең.
Гөлчәчкә, алдана күрмә — үземә кирәк, диген.

*2003*

* * *

Матур җәйдә корган оям көтмәгәндә таралды —
Бәгырем шартлап ярылды, ак йөзләрем каралды.

Оям белән килеп төште кеп-кечкенә кошчыгым —
Кан тамчысы сарган иде миңа сузган томшыгын.

Томшыктагы канны сөрттем, эчкә таммасын диеп,
Күкрәгемә кысып кочтым, куркып калмасын диеп.

Кошчыгым «кеше» булганчы, байтак гомерләр үтәр,
Канат яргач, Ходай кушып, үрләргә менеп китәр.

И Гөлчәчкә, һәр көн таңнан түзем сора Ходайдан,
Әҗере: үскәч кошчыгың ярдәм салыр һәркайдан!

*1982*

* * *

Саф йөрәккә Ходай бирсә шашып сөю
кайнарлыгы,
Хәтта Сират күперендә сизелер аның барлыгы.

Әгәр керсез мәхәббәткә үтеп керсә ялган, яла,
Рәнҗешнең үткен уклары җәзадай килеп кадала.

Гашыйкларны кайчак гыйшкы кара күмергә
калдырыр,
Аннан калган көл дә хәтта көчле ялкындай яндырыр.

Һич туктап калмас ут йөрәк, алдында биек тау
күреп.
Шашкын мәхәббәт — бер бәла, яуга кергән
гаскәр кебек.

Сөйгән ярларсыз йөрәкләр әйтерсең караңгы
бер баз.
Кояш яктысыннан гына яктыручы гаҗәеп аз.

И Гөлчәчкә, сөю — ләззәт. Табып мең төрле
әмәлен,
Сөйләсен сөю турында синең чарланган каләмең.

*2003*

* * *

Мин Ходайдан күпме үтендем,
йолдызларны урап мең килдем.
Күз яшемне гөлгә эчердем —
тиңем мине күрми микәнни?

Ничә еллар бөреләнмәгән
гөлем чәчкә атты күз-яшьтән.
Ә мин сулып, койдым чәчкәмне —
парсыз йөрүләрдән микәнни?

Юлларыма чыккан күп лә ул,
шашып сөйгәннәр дә сер түгел.
Тик канатым һаман ул түгел —
үз насыйбым килмәс микәнни?

Кай тарафта икән эзләре,
күрмәс булды мәллә күзләре?
Теләкләрем нигә үтәлми —
зарыкканны белми микәнни?

И Гөлчәчкә, берүк сабыр бул,
сабыр төбе, диләр, саф алтын.
Бәхет ул ярата көткәнне —
син шуны белмисең микәнни?

*1993*

* * *

Затлы күлмәгемне кидем, матур буламын диеп,
Син бәгырьдә булган чакта, дөньям да торды көлеп.

Балдай эчтем сулышыңны, таралды тәнгә бәлзәм,
Авыр минутларымда да яшәр өчен дәрт биреп.

Киттең дә баттың җиһанга — әйләнеп кайтырсыңмы,
Син китүгә җаннарымны борчулар басты килеп.

И йөрәгем, ярдәмең кыл, әрнүеңне җиңеләйт,
Рәхимеңне, шәфкатеңне яраңа капла сөеп.

Син шуны бел, и Гөлчәчкә: йөрәктәге яралар
Төзәлсә дә, үз урнына җөйләрне куя өеп.

*2003*

* * *

Чын сөюне татымаган, мәхәббәттән шашынмаган
кеше дә була икән.
Кызык: андый адәмнәрнең күңелләре, йөрәкләре
ни белән тула микән?

Зур сынаулар алып килгән, хәсрәтләргә күмеп йөрткән
үтә авыр көн туганда,
Юатучы, тыны бетсә, үз сулышын сулатучы
кешесе була микән?

Бар дөньясын оныттырып, сөю уты үзәкләрен
өтеп-өтеп алмаса да,
Күзе төшкән, якын иткән җанны уйлап сагынудан
йөзләре сула микән?

Гашыйклар янында йореп, өзелеп сөюләрен күреп,
көнчелек уты кабынса,
Бөтен җанын-тәнен биреп, үлеп яратасы килеп,
кызыгып куя микән?

Мәңгелек гашыйклар булып, һушлардан язарлык итеп
янып сөясе килгәндә,
Көткәннәре акланмаса, кемнәргәдер үпкә тотып,
кайнар яшь коя микән?

И Гөлчәчкә, мәхәббәттә яндың, көйдең, хисләреңне
мәңге сулмас гөлгә тердең —
Күңелләрең, бәгырьләрең сөюнең илаһи көчен
һаман да тоя микән?

*2003*

* * *

Җан кисәгем, сине көтеп уздырам көннәремне:
Йөрәгем — синең кулыңда, күзем — кайтыр юлыңда.

Ак чәчкәләр җыйган идек гашыйклар болыныннан,
Иң матур җыр туган иде яратышу турында.

Күз алдыма киләсең дә, тетрәнә бөтен җаным.
Бер мизгелгә дә югалтмыйм — син һәрвакыт уемда.

Йөгереп килеп чумар идем капкындай кочагыңа.
Рәхәт бер кайнарлык тоям бары синең куеныңда.

Сибелә чәчәк, түгелә җыр мәхәббәт иңгән җирдә.
Сөюнең керсезе туа хис дәрьясы буенда.

Тагын җыр язды Гөлчәчкә, каләмен хискә манып,
Бу җыр — янә бер мәдхия илаһи көч турында.

*2003*

* * *

Авыр уйдан арына күр, сөеклем,
Юкса мин теленгән йөрәк кебекмен.

Күзләреңдә ялкын күрсәм, сөеклем —
Сайрап туймас бер былбыл кош кебекмен.

Телләреңнән гөлләр тамса, сөеклем —
Сөеп туймас бер мәгъшука кебекмен.

Кулларыңның назын тойсам, сөеклем —
Синең өчен бик кадерле кебекмен.

Сине тоеп яшәгәндә, сөеклем —
Бәхетленең бәхетлесе кебекмен.

И Гөлчәчкә, язмышыңа мең рәхмәтләр әйтерлек,
Бары синең өчен яши сөеклең.

*2003*

* * *

Дистәләгән ел үтсә дә, онтылмый газиз балам:
Җаным үтәли тишелде, өзлексез яшем тамып.

Колагымда — ыңгырашу, күзләремдә — тилмерү.
Хәсрәтем гомерлек булды, йөрәккә уелып калып.

Күкрәк сөтем балам гомрен озайтты тик беразга.
Сулды йөзе, сүнде күзе, бер тәүлек уттай янып.

Кулларымда җанын бирде — күзләрен йомды арып.
Ташлады-китте, башымны тирән кайгыга салып.

Озын керфек, кыйгач кашлар күз алларымнан китми.
Сурәте һаман саклана, күз алмасында калып.

И балам, мине калдырып, кайларга киттең, кая?
Илерү кайтты әйләнеп, бәгырьне меңгә ярып.

Бала хәсрәтеннән авыр ни бар җирдә, Гөлчәчкә?
Бу хәсрәтне дә күтәрдең, башкадан гыйбрәт алып.

*2003*

# Дүртьюллыклар

Мәхәббәтне күккә чөйдем,
Чөнки үзем яндым, көйдем.
Ходам кушып, мин һәрвакыт
Үземне сөйгәнне сөйдем.

* * *

Синең белән язым, көзем,
Хәтта кышым чәчкә атты,
Күңелемә сүзең ятты,
Назларыңнан сулу капты.

* * *

Мин кырыкка төрләнәмен,
Булган чагыңда син янда.
Онытырсың дип борчылма,
Мин бит гел синең дөньяңда.

* * *

Китеп югалсам да «еракларга»,
Мин анда да сине көтәрмен.
Озак күренмәсәң, җаен табып,
Исләреңә төшереп китәрмен.

* * *

Тормыш куйган сорауларга
Юньле җавап тапмадым.
Гаҗизлектән йөрәгемне
Мең җәрәхәт каплады.

* * *

Җан сөйгәнем читтә чакта,
Чит миңа бар дөньясы,
Сагышлы итә җанымны,
Күзләремне күл ясый.

* * *

Тылсым илә аккан сүзең —
Челтер-челтер килгән чишмә.
Хикәятең тик безнең сер,
Син аларны ятка чишмә.

* * *

Күз алларым томалана
Син күренми торганда,
Ике күзем дүртәр була,
Сине каршыларга чыксам
Син кайтасы юлларга.

* * *

Исемеңне көнгә мең кабатлыйм —
Ишетәсең микән, юк микән?
Сөю дәрте кергән йөрәгеңдә
Төтен генә микән, ут микән?

* * *

Йөзләреңне күрмәгәнгә «ел» бит инде,
Сагынудан ике күзем күл бит инде,
Арабызда ике атлам юл бит инде —
Киртә булырдай һичнәрсә юк бит инде.

* * *

Син генә дип, чит-ятларга
Хәтта күз дә салмадым.
Күпме еллар бары сиңа
Күңелемне багладым.
Тик синең пар түгеллекне,
Кызганыч: соң аңладым.

## Һ

## Робагыйлар

И гүзәлем, сине күпме көтеп була,
Йөрәк белән җанны күпме өтеп була?
Менә сиңа — көем, бусы менә — өем:
Иясе бул! Ату җеннәр кереп тула.

* * *

Акыл иясеннән раслат:
Сөю, яра — бербөтен,
Аерылмас туганнардай —
Ут, ялкын, кара төтен.

* * *

Тормышыңда яр булырмын мәңгелек,
Аңласаң әгәр җанымны иң элек,
Терәк булсаң бөтен гомерем буена,
Хыянәтне һич китермәм уема.

* * *

Бәгыремә әрнү-сагыш тулмаса,
Телләреңә яман сүзләр кунмаса,
Төннәремдә яшьле мендәр тормаса —
Кадерленең кадерлесе булырсың.

Әйтер булсаң телеңә ни килгәнне,
Ишәр булсаң мин тилмереп өйгәнне,
Әйләндерсәң яшькә минем көлгәнне —
Сәхраләрдә калган гөлдәй сулырсың.

* * *

Сүрелмәгән чын мәхәббәт —
Йөрәкләрнең зирәклеге,
Ә зирәклеккә өстәлә
Рух һәм акыл кирәклеге.

* * *

Сөйгән, сөелгәннәр өчен
Ачык булыр бөтен капка,
Бары гүзәл җанда гына
Бәхет чәчкәләре калка.

* * *

Балкып торган йөз алдында
Кара йөзләр дә тез чүгә,
Кара уе гамәленнән
Китәләр хәтта йөзтүбән.

* * *

Өрсен «этләр» — барыбер кермәс
Ни исәпкә, ни санга,
Сикереп тә буе җитмәс
Ни дәрәҗә, ни шанга.

* * *

Миһербанлы җаныңа мең-мең рәхмәт,
Йолдыз булып балкыр ул киң галәмдә.
Синнән килгән яхшылыклар югалмас —
Һичьюгында калыр минем каләмдә.

* * *

Кемдер сине өзелеп көтмәсә,
Көнгә мең әйләнеп үтмәсә,
Йолдызларга алып китмәсә,
Читкә куеп дөнья хәсрәтен.

Назга күмеп, кочып үпмәсә,
Юлларыңа гөлләр сипмәсә,
Йөрәгендә сөю йөртмәсә —
Мондый яшәүнең ни рәхәте?

* * *

Бу дөньяда кем бар икән
Яры өчен хыялында
Алтын сарай кормаган,
Мәхәббәт уты өстендә
Чак эленеп тормаган?

Төшеп китеп, янып бетеп,
Көл булмам дип уйлаган,
Кара күмергә калдырып,
Ялкын өтеп алганда да,
Сөюеннән туймаган?

* * *

Зәһәр сүзләр чәнчеп үтермәсен дисәң,
Усал телне аркылыга тешләп була.
Ә йөрәгең акылыңа буйсынмаса,
Йә, әйтегез, бу хәлләрдә нишләп була?

* * *

Шома егет ятьмәсенә бер эләксәң,
Бик тиз генә котылырмын димә аннан,
Ярый ла бетә ахыры шатлык белән —
Вәгъдәләре булса чеп-чи ялган.

* * *

Кырыс вакыт әйләнмәсе,
Бөтереп алып эченә,
Бер батыра, бер калкыта,
Этеп барлык көченә.

* * *

Башны йөрәк кайнарлыгы
Ташлап тора кайчакта.
Нәкъ шулчак була могҗиза —
Акыл хистән качмакта.

* * *

Зирәк затлар акыл белән эш итәр,
Тигезләр һәрчак аңсызлар уйганны,
Энәне гел өстен куяр кылычтан —
Энә тегәр үткен кылыч кыйганны.

* * *

Корал итеп алма син тупаслыкны,
Әдәплелек — акыллылык билгесе.
«Тинтәк бит ул» дәрәҗәсе алма син,
Кеше алдында көлкегә калма син.

* * *

Дуслар бәхәскә керешсә, берсе юл куярга тиеш,
Аларны бәйләп торткан дуслык җебен өзмәс өчен.
Ике яклап нығытып тартсаң, юан аркан да өзелер,
Дуслыкны бетермим дисәң, син сарыф итмә көчең.

* * *

Бөтен җирдә намуслы дигән дан алсаң,
Ихтыяҗи ялган сүз дә эзсез үтмәс.
Әгәр һәрчак алдакчы булып күренсәң,
Дөрес сүзең дә һичкемгә тәэсир итмәс.

* * *

Әдәпсез сүзләргә һич иярләнмә —
Тупаслык яктыртмый адәмнең йөзен.
Ихтирам чәчсәң, үсәр мәрхәмәтлек,
Затсыз булсаң, көтмә игелек үзең.

* * *

Язмыш илне һәм буыннар васыятен
Сатып җибәргән кешене ят итә.
Шәм ялкынга азык биреп торса да,
Ахыр чиктә үзе дә янып бетә.

# Шаян такмаклар

Сандугачлар кунмый китте
Сагышлы талларыма,
Минсез каласың килмәсә,
Кайтып җит яннарыма.

Сулар аша, күпер итеп,
Сузып салганнар каен.
Озак күрми торсаң мине,
Югалтуың бар, җаным.

Өстеңдәге ак күлмәгең
Бик килешә үзеңә.
Әллә нинди уйлар төшә,
Күренмәсәң күземә.

Мин киләсе чатырыңны
Гөлләр арасына кор.
Борчу салма йөрәгемә,
Күз алдымда гына тор.

Беләзегем елтыр көмеш,
Бизәкләре карадан.
Ходай кушса, хәтта җил дә
Үтмәс безнең арадан.

Беләзегем киң икән,
Беләгемә тиң икән.
Сагынмасаң күренмә дә,
Сагынсаң очып кил, иркәм.

Әйдә, сиптер гармуныңны,
Күпләр көнләшсен әле.
Ярата белмәгәннәргә
Сөю өләшсен әле.

Кулыңдагы йөзегеңнең
Исеме Азат икән.
Сөймәсәң дә азап икән,
Сөйсәң дә газап икән.

Йөри күрмә берьялгызың
Дуслар җыелган җиргә.
Бары минем белән генә
Урының булыр түрдә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гыйнулла.
Ак йөзләрем саргайганчы
Көттермәсәң ни була?

Күзләремдә үпкә уты
Кабат янмасын иде.
Синсез үткәргән төннәрем
Кабатланмасын иде.

* * *

Син юк чакта талларыма
Бер ят кош та кунмады,
Хушлашканда рәхәтләнеп
Үбешеп тә булмады.

Һаман түбәнтен очасың,
Югарырак оч әле,
Сыйпаштыргалап торганчы,
Иркенләп бер коч әле.

Йөрмә әле чит җирләрдә,
Үз җиребез дә әйбәт.
Сөюләрең ихлас булса,
Беркем сөйләмәс гайбәт.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Хәбибулла.
Әллә кайдан ураткачы,
Туры әйтсәң ни була?

Сагынып саргаеп беттем —
Кайларда йөрисеңдер?
Сагышымны таратырга
Ник һаман килмисеңдер?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлҗиһан.
Синең мине сөюеңне
Белә инде бар җиһан.

Ник хисеңне яшерәсең?
Белмиләр дип уйлама.
Сөюгә мәдхия җырлап,
Үзең чәчтең дөньяга.

* * *

Сары сандугачлар булып,
Талларга кундың мәллә,
Борын чөеп утырасың,
Әллә кем булдың мәллә?

Күпме генә тырышсаң да,
Кызулап киталмыйсың,
Артымнан куып маташма —
Барыбер җиталмыйсың.

Кашың-күзең җимерелгән —
Кәефең китте мәллә,
Өмет итеп йөргән ярың
Карамый үтте мәллә?

Кырык ямаулы шарфыңны
Һаман бәйлисеңмени?
Яңасын сатып алырга
Акча җәллисеңмени?

Борын чөеп, мин кем, диеп,
Кайларга киттең инде?
Һаман читкә йөри-йөри,
Бозылып беттең инде.

Күпме гомер пыскыйсың бит,
Һаман кабыналмыйсың.
Мунча парың бетә инде,
Һаман чабыналмыйсың.

Бу кызларга күз кыздырма —
Егетләре мишәрләр.
Ату ипи шүрлегеңә
Бик тиз менеп төшәрләр.

* * *

Егетләр тарта тәмәке,
Кызлар тарталар сөрмә,
Белер-белмәс сүзләр сөйләп,
Гөнаһысына кермә.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ташбака,
Миңа тиң булырдайларны
Күрмимен әле пока.

Инеш аша басма салдым,
Чыгам дисәң, чыгып кал,
Гайбәт сатып йөргән өчен
Адәм хурлыгына кал.

Тиреңә сыеша алмый,
Котырынып өрмә син.
Үзең булдыралмаганга
Эчең пошып йөрмәсен.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Җамалый,
Синең кебек хөрәсәннәр
Кеше малын чамалый.

Җиде такта арасыннан
Чыгып тора бер колга,
Исән-имин яшим дисәң,
Төшмә син минем юлга.

Югарочтан түбәночка
Төшеп килә кырмыска,
Бер асыл кош, бер усал кыз
Буласың бу тормышта.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр әфлисун,
Авыз-борының кыек мәллә,
Ник битеңне каплыйсың?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әкълимә,
«Әйт» дигән һәрбер кешегә
Беркайчан да «һәйт» димә.

Кызлар килә гармун уйнап,
Башларында ак яулык,
Сез дусларга, туганнарга
Телибез бәхет, саулык.

Йөгәнсез тел — киле сабы,
Төя дә төя генә.
Акыл аша үтмәгән сүз
Элә дә чөя генә.

Йөрәгеңне бикләп куйгач,
Ялкын туламыни ул,
Тәнне, җанны тетрәтмәгәч,
Сөю буламыни ул?

Тормыш зәхмәтләре кебек
Аяк чалучы сирәк,
Аның һәр чәнечкесенә
Түзә белергә кирәк.

Еллар узды, башмак тузды,
Чәчең тулы көмеш бәс,
Бу яшеңдә ярдан ярга
Күчеп йөрү килешмәс.

Мин шаярттым, син тыңладың —
Этлек белән түләмә.
Матри, малай, бу хәлләрне
Беркемгә дә сүләмә.

* * *

Күзләреңне майландырып,
Каршыма чыкма әле,
Җаныма үтәргә теләп,
Куллардан тотма әле.

Айга бер тапкыр булса да
Көзгегә карыйсыңмы?
Көзгедәге сурәтеңдә
Үзеңне таныйсыңмы?

Танысаң, нигә чыгасың
Маймылланып каршыма?
Таракан булып төшәсең
Һәр пешергән ашыма.

Ай-һай, бизәкләп сөйлисең,
Хыялыңа чумдырып,
Иярчен кук ник йөрисең,
Башың-кузең тондырып.

Пәригә охшап, чәчеңне
Ник буядың карага?
Туры әйткәнгә кузеңне
Әйләндереп карама.

Иләк хәтле авызыңа
Көн дә чүбек тутырма,
Белер-белмәс башың белән
Гайбәт сатып утырма.

Әнә тора автомобиль,
Төяп куйганнар печән.
Ник болай терәлеп каттың? —
Әйтерсең лә туң кучән.

Авызыңны бик зур ачма,
Кидермәсеннәр нукта.
Җелегемә үттең инде,
Көнләшүеңнән тукта.

Өйләнәм дип сайрама да,
Синдәй иргә кем килсен,
Хөрәсән ялкавы белән
Ничек итеп көн күрсен?

Хак сүзгә ачуың килеп,
Ник йөзеңне караллтың?
Кешегә үпкәлисең юк —
Җимерек өең, каралтың.

Кызларны хурлап торганчы,
Тормышың рәтлә башта.
Кеше рәтенә керүгә,
Булырсың күздә-кашта.

Быел да уңмаган икән
Бодай белән арышың.
Зәһәреңне чәчә-чәчә,
Кая китеп барышың?

Йөрәгемнең кесәләрен
Хатлар белән тутырдың.
Кылдан нечкә күңелемә
Юшкын булып утырдың.

* * *

Сайрар кошлар очып киткән
Без сыенган тирәктән.
Инде кырып ук ташлармын
Син юньсезне йөрәктән.

Ярату көткән йөрәкне
Яндырдың да көл иттең.
Син бит мине чит күзләрдән
Яшереп тоткан гөл иттең.

Сагыш дәрьялары тирән,
Ничек гизәрсең икән?
Үтеп бара әй гомерләр,
Шуны сизәсең микән?

Сизмисеңдер, сизсәң әгәр
Болай йөремәс идең.
Көйдереп торган эсседә
Тунга төренмәс идең.

Башыңны җүләргә салып
Узып киткән буласың.
Икәүдән-икәү калганда,
Күзең алмый торасың.

Сөймәдем, дия алмыйсың —
Чәчең чәчкә бәйләнгән.
Яшереп маташма, күптән
Башың-күзең әйләнгән.

Һуштан язып сөюеңне
Бик тиз сызып ташлама.
Сөйгән ярың рәнҗеп калса,
Борчу-хәсрәт башлана.

Иң кадерле хисләреңне
Йөрәгеңдә саклап йөр.
Каралтма да, югалтма да,
Якты, матур төскә төр.

Рәхәтлектән дөньяң онытып,
Башка көлмәссең инде.
Шашып бетеп, көчле итеп
Башка сөймәссең инде.



# Поэмалар

# Мең еллардан килгән тарихлы без

## Кремль диварлары янында

### I. Эзләп йөрим милләт бишеген

Шул диварлар кырына килеп бассам,
Ачып керәм тарих ишеген,
Төшәм аның тирән катламына,
Эзләп йөрим милләт бишеген.

Бик күрәсем килә минем аны,
Ни икән ул безне тирбәткән,
Канга кояш кайнарлыгы салып,
Йөрәкләргә ялкын дөрләткән?

Таба алмыйм һаман шул бишекне,
Йөзәр катлам аны яшергән,
Өстәвенә дәрьялары тора
Милләт каны һәм күз яшеннән.

Бәлки әле шушы кан белән яшь
Нығыткандыр татар тамырын,
Сугаргандыр татар торган җирне,
Кабат үссен диеп ябырылып.

Шуңадыр, шәт, татар гомере буе
Милли горурлыгын саклаган,
Муенына балта чапканда да
Үз дәүләтен, данын сатмаган.

Бер дә юкка монда тезелешмәгән
Җәлил, Алиш, Баттал, Кормашлар.
Йөзләрендә калган бер каһкаһә,
Тәгәрәшеп киткәч тә башлар.

Китсә дә баш, халкы хозурына
Кайтты алар хәтта ташларда,
Татар милләтенең беркайчан да
Сатлык түгеллеген расларга.

## II. Үз кыйблаңа һәрчак табыну кирәк

Капкасыннан керәм ак кальганың,
Саклык белән басып җиренә.
Ыңгырашкан тавыш ишетелә
Шәһит киткәннәрнең гүреннән.

Әллә инде газиз башларына
Басып йөрим микән белмичә?
Булуы да мөмкин: бит аларның
Чәчелеп яткан җире берничә.

Зур дәһшәттә чабылган баш-кулның
Исәп-хисабы да булмаган.
Явыз Иван байтак милләтләрнең
Язмышларын «чөеп уйнаган».

Һәр «чөелгән» язмыш, нык үзгәреп,
Төшү белән чәчрәп сибелгән.
Берегеп калганнары кимсетелеп
Җәберләнгән, эттәй тибелгән.

Безнең язмыш та шул: әмма халкым
Рәнҗесә дә, ачу сакламый.
Әллә шуңа кайбер милләттәшем
Сан исәбен җайлый башканың.

Чит эргәдә соңра табып булмас
Югалтканны, күпме эзләмә.
Үз кыйбланңа һәрчак табыну кирәк
Калыр өчен милли эзләрдә.

Бары тик шул эзләр алып чыгар
Зур дөньяга эшчән татарны,
Күптән вакыт инде агартырга
Хаксыз яккан кара тапларны.

Борынгыдан кемнең кем булуын
Исләрендә һаман тотсынга,
Төрле милләт халкы арасында
Аңлашу һәм хөрмәт булсынга,
Язмыш-тарихларын белү кирәк
Татарына, чуаш, русына;
Киләчәккә китәр милләтемнең
Бәгырендә иман тусын да
Изге дога булып ирешеп торсын
Шәһит Колшәрифләр рухына.

## III. Колшәриф

Казансуны тутырып татар каны,
Мәетләрдән изелеп татар җаны
Бөелә-бөелә аккан бер мәлдә,
Шәһит киткәннәрнең исемнәре
Килер буыннарга күчкән дә
Хакыйкатьне гел агартып тора,
Хәтерләрне гел яңартып тора
Гасырларны узган көннәрдә.

Милләт бәйсезлеген сакларга дип,
Газиз җиребезне якларга дип,
Гарасатның канлы дәһшәтенә
Халкы белән кергән Колшәриф.

Җимерелгән кальга урынында
Кырылып яткан яугирләр турында
Алтын юллар тезгән чал тарих.

Фәлсәфәче, шагыйрь, сәясәтче,
Казан ханлыгының имамы
Колшәрифнең чиксез зур абруе
Бәк, морзалар, кыйбла табалмыйча,
Төрле якка сугылып йөргәндә дә
Саклап калган милләт иманын.

Яраннары, якыннары белән
Казан әйләнгәндә ат менеп,
Ихтирамга һәм зур данга күмеп,
Сәламләгән бар да бил бөгеп.
Аны күргәч, хәтта Хан ат төшкән,
Сәламне дә әүвәл үзе биргән,
Хушлашканда хөрмәтенә төргән,
Чапаның итәген үбеп.

Зирәклеген, гыйлемлеген җигеп,
Казан белән Мәскәү арасында
Күп эшләрне җайга салган ул.
Яхшылыкка яман җавап биргән
Кара гяур котырынгач кына
Кулына кылыч, калкан алган ул.

Явызлыгын җуймас, нәфесе туймас
Иван козгыннары, өерелеп,
Җиребезне килгәч таптарга,
Шәкерт, муллаларны яугир итеп,
Дошман яуларына каршы китеп
Ут уйнаткан алгы сафларда.

Тик кайда соң, кайда илаһи көч,
Хыянәткә каршы торырлык,
Бугазыннан алып, бер селтәүдә
Юк булганчы җиргә орырлык?

Җиңеп булмый торган шул хыянәт
Җиткән Колшәрифләр башына.
Инде ничә гасыр истә саклап,
Баш орабыз хәтер ташына...

Казансуны тутырып татар каны,
Мәетләрдән изелеп татар җаны
Бөеләә-бөеләә аккан бер мәлдә,
Шәһит киткәннәрнең исемнәре
Килер буыннарга күчкән дә
Хакыйкатьне гел агартып тора,
Хәтерләрне гел яңартып тора
Гасырларны узган көннәрдә.

*2003*

# Капка

## I. Әби

Дистәләгән елны алып ташлап,
Кайттым әле үсмер чагыма:
Күзгә сарган энҗе тамчыларда
Шул чакның бер көне чагыла.

Утырдым да каршыдагы йортның
Бакча буендагы тактага,
Хатирәләр эргәсеннән киттем,
Ә күзләрем безнең капкада.

Кемдер кинәт, йомшак кына итеп,
Капка келәсенә кагылды,
Әби икән, чыга-чыгышка ук
Озын итәгенә абынды.

Карап алды шундук як-ягына,
Догасын һәм әфсен укынып,
Китеп барды аннан түбән очка,
Җил-җил атлап, давыл, ут булып.

Кызулаган саен ак күлмәге
Өермәдәй барды артыннан,
Сихәт илтә китте булса кирәк
Бала көткән яшь бер хатынга.

Шулай йөри инде дәшкән саен,
Карамыйча җил һәм давылга,
Җиде баласына әни булса,
«Кендек әби» бит ул авылга.

Күпме бала аның кулы аша
Җиһаннарга аваз салгандыр,
Күпме парның чиксез рәхмәтләре
Савап булып өелеп калгандыр...

**Әбиемнән әле үз гомерендә**
**Меңнәр китте арынып мең чирдән,**
**Сызлауларын басар өчен халык**
**Килә иде хәйран күп җирдән.**

**Ул гына да түгел: биш ятиме —**
**Биш оныгы булды кулында,**
**Хәл килгәнчә булышып, һәммәсенә**
**Терәк булды тормыш юлында.**

**Әбиемне шушы яхшылыгы,**
**Шул рәхмәтләр имин йөрткәндер.**
**Бу дөньяда әле мин кирәк дип,**
**Туксаныннан узып киткәндер...**

**Табигатьтән көчле иде әби**
**(әле безгә дә шактый күчкән ул):**
**Кайнап торган зур самавыр белән**
**Өй базына егылып төшкән ул.**

**Артык зыян күрми генә шунда**
**Исән калган, Хода рәхмәте.**
**Чирләп ятканын да беркем белми —**
**Китермәгән иблис зәхмәтен.**

**Үз җирендә урак урган чакта**
**Уеп алгач учының яртысын,**
**Бер уч тоз сипкән дә шул ярага,**
**Дәвам иткән эшен ярсынып.**

**Укымышлы иде безнең әби,**
**Үзе кебекләрне иш итте.**
**Гарәп, төрек, фарсы, рус сүзләрен**
**Әбиемнән әүвәл ишеттем.**

**Ул гынамы? Байбичәләр булып**
**Йөргән әби, туганнар дәшкәч,**
**Ике кызын утырмага йөрткән**
**Күрше авылдагы кардәшкә.**

**Баганалы авылы кыркапканы**
**Каерып ачкан ак пар ат күреп,**
**Килү белән әби, апаларым**
**Авыл әйләнгәннәр иң элек.**

**Гани байның ишек алларына**
**Чабып килеп кергән атларны,**
**Урнаштырып, өйгә кергәч кенә**
**Ябып куйганнар зур капканы.**

Әби, әби! Бер дә картаймыйсың,
Югыйсә бит йөзне вакладың.
Озын зифа гәүдәң бөкрәйсә дә,
Дәрәҗәңне һәрчак сакладың...

...Шул арада әби кайтып җитте —
Тиз беткәндер эше, күрәсең,
Тагын шулай җил-җил кереп китте,
Шалтыратып капка келәсен.

## II. Әни

Тукта! Кем булыр бу? Атлый-чаба
Безнең өйгә таба кем килә?
Әни ич бу, озын тәнәфестә
Бала имезергә йөгерә.

Хәле китеп, азрак тын алыйм дип,
Капка келәсенә тотынды.
Бераз басып торды тыныч кына —
Авыр сулуыннан котылды.

Ә аннары кинәт каударланып,
Ачып керде авыр капканы,
Тизрәк-тизрәк, инде киту кирәк —
Сәгатьләп торырга кайтмады.

Тамак туйгач тынып йоклап киткән
Баласына ябып япманы,
Чыгып чапты, тамагына үзе
Әллә капты, әллә капмады.

Очты гына күпер, сулар аша,
Соңга калмыйм диеп, дәрескә.
Сиксән дүрт күз берни сизми калды —
Шулай өлгер иде һәр эштә...

**Безнең әни уңган гына түгел,**
**Чибәрләрнең булган чибәре.**
**Әти аны белеп сайлап алган,**
**Йөз гүзәлне читкә тибәреп.**

**Әтиемә аны бүләк итеп**
**Үстергәндер Байлар Сабасы,**
**Чистай — Саба каннарыннан туган**
**Чәчрәп торган мишәр баласы.**

**Бер генә дә түгел, унбер Тархан**
**Аваз салган ошбу дөньяга.**
**Тик тугызы гына яшәп калган**
**Юлын алып милли кыйбладан...**

**Узган гомерләрдән бер әйләнсәм,
Хәйран калып торам кайчакта:
Тугыз гына бала үсмәгән бит
Безгә генә дигән кочакта.**

**Дүрт ел саен кырык ике сабый,
Белем генә түгел, наз алып,
Әниемнән әтиемә күчкән
Төрле сыйныфларга таралып.**

**Балалары очкан тугыз тараф
Аның өчен кыйбла булгандыр.
Һәр көн саен шушы тарафларга
Теләк теләп дога кылгандыр.**

**Изге теләкләре кабул булды —
Олы юлдан туры барабыз.
Безне саклап гел янәшә атлый
Ару белмәс Газиз Анабыз.**

...Әни кабат киткәч мәктәбенә,
Капка торды бераз «тын алып».
Бала-чага иртүк, чыр-чу килеп,
Беткән иде инде таралып.

Көн авышты. Шалтыр-шолтыр килеп,
«Хәлдән тайды» капка келәсе,
Әле тагын әти кайтасы бар —
Гаиләнең иң зур түрәсе.

## III. Әти

Һәм, ниһаять, салмак кына атлап
Кайтып килгән әти күренде.
Ашыкмыйча гына килде дә ул
Капка келәсенә үрелде...

**Чибәр кеше иде безнең әти**
**Зәңгәр күзле горур бер мишәр.**
**Ни кызганыч: инде ничә еллар**
**Кабер өсләрендә җил исә.**

**Бик тә моңлы иде безнең әти —**
**Уйнамаган көе булмады,**
**Баян, гармун, скрипкаларны**
**Ут уйнатты аның куллары.**

**Гаҗәп уңган иде безнең әти —**
**Эшләмәгән эше юк иде,**
**Аның чиксез тырышлыгы белән**
**Тугыз бала бөтен, тук иде.**

**Балаларын нык яратты әти —**
**Алларыннан төшми үстек без,**
**Тырышлыгын, зыялыгын алып,**
**Дөнья киңлегенә күчтек без.**

**Әйбәт кеше иде безнең әти —**
**Берәгәйле горур бер мишәр,**
**Ни кызганыч: инде ничә еллар**
**Кабер өсләрендә җил исә.**

...Туктап калды әти, әллә инде
Минем күзәтүне сизенеп,
Борылды да миңа таба карап
Озак торды, куйды көрсенеп.

Кереп китте. Балалары дәррәү:
«Әти кайтты, әти», — диеште,
Әни өстәл япты, әтиемә
Салып куйды иң зур өлешне.

Өй эчендә, сүзгә урын куймый,
Унбер кашык «өзелеп җырлады»,
Өй кырында үскән таллары да
Шаулавыннан озак тынмады.

Ут алдылар. Кинәт салмак кына
Моң таралды ачык тәрәздән,
Кыңгыраулы гармун башлаганны
Дәвам итте баян бераздан.

Баян тынып калгач, үзәкләрне
Скрипка кылы өздерде,
Арыса да, әни җыр башлады,
Гүя моңнар аңа көч бирде.

Без кушылдык әни җырларына,
Әти көе безне биетте.
Алар безгә салган барлык сыйфат
Киләчәктә безне үз итте...

Мин боларны күрше эргәсеннән
Уелыплар төшеп тыңладым...
Түзалмадым: ятим өебезнең
Инде кыйшык капкасыннан кереп,
Баскычына ятып еладым.

*2002*

# Беренче сентябрь хатирәсе

## I

Бүгеннән көз җиргә аяк басты:
Алтын яфрак тезә юлларга.
Шау-гөр килеп, укучылар атлый,
Чәчкә бәйләмнәре кулларда.

Шул чәчкәләр һәр сентябрь саен
Күңел тәрәзәмне кагадыр.
Ни дисәң дә, минем тамырларда
Укытучы каны агадыр.

«Апа, апа!» — диеп, эземә басып,
Күпме бала йөрде янымда.
Игътибардан мәхрүм калмасын дип,
Күз уңында тоттым барын да.

Хәтерләрдә, борын тарта-тарта,
Бик тырышып язган чаклары.
Берәүләре телдә бик сай йөзсә,
Кайберсенең
Аксый иде хисап яклары.

Бергәләшеп шактый хезмәт куйдык
Тигезләргә бөтен якны да.
Тиз бетердек каләм очларыннан
Дәфтәрләргә тамган тапны да.

Уртак хезмәтебез буш китмәде —
Нәтиҗәсе күренә бүген дә:
Бала чактан тырышканнар чөнки
Хисабын да белә, телен дә.

Истә... истә (әмма күпләренең
Исемнәре менә онытылган)...
Өмет тулы мөлдерәмә күзләр
Уяталар һаман йокымнан.

## II

Сентябрьнең иң беренче көне —
Яуширмәдә белем бәйрәме.
Урам тутырып бара яше-карты,
Һәрберсендә чәчәк бәйләме.

Шул агымга кушылып, мин дә киттем,
Газиз әниемне җитәкләп.
Ашкынуын баса алмый йөгерә —
Бик якын шул аңа бу мәктәп.

Спорт залы тулды халык белән,
Бер урын юк аяк басырга.
Әниемә зурлап юл бирәләр —
Өч буында үскән балаларга
Белем бирде узган гасырда.

Тәрәзләрдән авыл өсләренә
Милли көйләр, җырлар агылды.
Шул арада «япь-яшь» әниемнең
Инде әби булган укучысы
Беләгенә килеп кагылды:

«Әй-й, апа җан, апа канатым!
И яраттык та соң без сине.
Бер әүлия урынына күрдек —
Синдәйләрнең булмыйдыр тиңе.

Син бит әле берни белми калдың,
Һәр көн кичен бергә җыелып,
Тәрәз буегызда күпме йөрдек,
Шаулашудан көчкә тыелып.

Пәрдә читләреннән күзли идек,
Ничек йөри диеп, өендә.
Уйлый идек: ашый, эчә микән,
Йоклый микән башка кешеләр күк,
Нинди хәлдә, нинди киемдә?

Бервакытны шулай күреп алдык
Чәйләр эчеп торган чагыңны.
Инде китте кәеф, китте кәеф —
Дошман иттек сезнең табынны.

Әйтерсең лә ул гаепле инде
Син дә ашый торган булганга.
Шуннан ары күзәтмәскә булдык,
Күңелләргә ачу тулганга.

Үпкәләрне озак сакладык без,
Вакыт үткәч, барыбер онытылды.
Безне ихлас яратканың өчен,
Бу «гаебең» эчкә йотылды.

И-и, апа җан, апа канатым,
Яратып та сине карадык!
Синнән бит без башка сыйныфларга
Елашыплар бетеп таралдык.

Мәктәп бетергәнче ябылмады
Син укыткан сыйныф ишеге:
Башка сыйныфларда укыганда
Очратмадык синең ишене.

Шуңа күрә җае чыккан саен
Бөтерелдек синең тирәңдә,
Ике якның шулай тарту көче
Яткан булса кирәк тирәндә.

Ә Тарханов абый[1] — үзенә башка —
Авызына гына каратты.
Физикасын ныграк яратса да,
Безне дә үзенчә яратты.

---

[1] Әтиемне укучылар шулай йөртә иде.

Чиксез иде аңа хөрмәтебез —
Тик нигәдер аннан шүрләдек.
Кырыс булды, әмма беркайчан да
Усал мөнәсәбәт күрмәдек.

Үз итмәде бары ялкауларны,
Наданга да бераз эләкте.
Такта янда миңгерәпләр торсаң,
Борып кына алды колакны.

Дөрес, кызлар башка чутта булды,
Малайларны кертте тәртипкә,
Алар халкы бик хәйләкәр бит ул —
Зарланалар иде эш күпкә.

Ә бит аның тырышлыгы белән
Безнең кулда
Мандолина, баян уйнады.
Күп нәрсәгә өйрәтте ул безне,
Моннан булмый, диеп тормады.
(Җиңел булсын авыр туфрагы!)

Шуңа күрә сезне авыл халкы
Искә төшерә һәрчак хөрмәтләп...
Сау торганны менә шулай итеп
Чакырып алып, һәр ел күрештерсен,
Очраштырсын иде бу мәктәп», —

Дип тезде дә борылып китеп барды,
Үсеп беткән оныгын җитәкләп.
Әллә ничә борылып карый-карый,
Рәхмәтләрен әйтеп хикмәтләп.

Хәйран булып тыңлап тордым аны —
Менә бу — дәрәҗә, ичмасам.
Хәзергеләр мондый бөеклеккә
Җитә алмас инде һичкайчан.

III

Яуширмәдә бүген белем көне,
Бөтен авыл зурлый бәйрәмне.
Төрле яктан кунаклар да кайткан —
Һәрберсендә чәчәк бәйләме.

Хәерле сәгатьтә, укучылар! —
Гыйлем юлы шактый катмарлы.
Зур тырышлык кирәк үтәр өчен
Берәм-берәм барлык катларны.

Көн күрмешең якты булсын дисәң,
Белем кырың бирсен зур уңыш.
Моңа ярдәм итсә укытучың,
Җавап итеп аңа син булыш.

Белемсезләр Илгә кирәк түгел,
Җиргә кирәк түгел наданнар.
Бүтән өчен беркем хезмәт куймас —
Нык үзгәрде хәзер заманнар.

Башлыйсыз сез тәүге уку көнен
Теләкләргә, гөлгә күмелеп:
Китәр сукмакларда юлдаш булып,
Саулык килсен сезгә иң элек.

Аннан килеп, камил акыл белән
Тулы зиһен сездән калмасын.
Күңелегезгә тулган игелекне,
Изгелекне һичкем алмасын.

Хәерле юл сезгә, хәерле юл,
Зур уңышлар шушы юлларда!
Онытмагыз:
Илнең генә түгел, хәтта Җирнең
Киләчәге сезнең кулларда!

*2003*

# Хезмәтенә күрә хөрмәте

*Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинга*

## I. Бәхет капкасы

— Иртә таңнан, бик тиз торып,
Капкаларны ач, балам.
Кешеләргә бәхет керә
Бары ачык капкадан.

— Алайса, әби, капканы
Кичтән үк ачып куям.
Бәхет керер өерелеп —
Таң белән үзең уян.

— Юк, балам, көфер сөйләшмә,
Тормышың булмас бөтен.
Ул чагында төн эчендә
Чыгар кергән бәхетең.

*Кечкенә Фатыйхка әбисе*
*биргән гыйлемнән*

Кайда булса, шунда таңнан торып,
Ачып куйды каерып капканы.
Шуңа күрә язмыш сызган юлдан
Үз бәхете белән атлады.

Кечкенәдән иңгән бу хакыйкать
Юлдаш булды авыр тормышта.
Дөрестән дә, бәхет килә икән
Чык кипкәнче торып тырышсаң.

Кырларында хуҗа итеп йөртте
Арча, Балтач, янә Мамадыш.
Хөрмәтләре хезмәт белән туды —
Төрле яклап килде казаныш.

Бер гадәттән арыналмый һаман:
Хет ничәдә йокыга ятмасын,
Таң нурлары белән бергә торып,
Ачып куя бәхет капкасын.

## II. Тормыш арбасы

— Беркөн шулай әби белән
Печәнгә диеп киттек.
«Уф алла»ны тутырдык та
Кайтасы юлга төштек.

Әби әйтә: «Мин, улым, — ди, —
Арттан этим арбаны,
Син, артка карамый гына,
Алдан тартырсың, яме.»

Әй тартам мышнап, кайчакта
Җиңел булып та китә.
Җиңел булмыйча, арттан бит
Әбием бик нык этә.

Этә-тарта бик тиз кайттык —
Икәүләп сизелми дә.
Артка борылып карасам,
Әбием күренми дә.

*Кечкенә Фатыйхка әбисе*
*биргән гыйлемнән*

Нинди генә эштә эшләмәсен,
Кай якларга гына бармасын,
Арттан эткәннәрен көтеп тормый,
Җигелеп тарта тормыш арбасын.

Яшьтән иярләде бар эшне дә,
Яулый алды халык күңелен.
Тырышлыгы белән исбатлады
Битараф һәм ялкау түгелен.

Үз хезмәте белән ияртте ул
Олысын да, хәтта кечесен.
Ияртүчең шундый өлгер икән,
Эшләмәс җиреңнән эшлисең.

Әле бушап, әле тулып тора
Язмыш белән тормыш арбасы.
Узар гомер алда биниһая —
Арбаларны эздән ут чыкканчы
Тартасы да әле тартасы.

## III. Нурлат

— Сеңлем, ник һаман килмисең?
Кайчаннан бирле көтәм.
Чакыруын чакырам да,
Кычытканлы юлларында
Батып калмассың микән?

Мамыкка, ансы, җитәрсең,
Арырак та китәрсең.
Тик безне эзләп тапканчы
Җәфаланып бетәрсең.

Шулай булса да кил инде,
Бераз бездә торырсың.
Юл булганны көтсәң монда,
Гүр иясе булырсың.

*Кычытканлы авылында*
*яшәгән апамның кайчандыр*
*әйткән сүзләре*

Моннан бик күп еллар элек мине
Апам утырмага чакыргач,
Курыктым да юлга чыкмый калдым,
Киләм, дидем, юллар яхшыргач.

Озак көттем — апам гүр иясе,
Күрә алмый калды килгәнне.
Көзгеләргә охшаш юл агышын,
Барлык өйгә газлар кергәнне.

Хәзер монда хәлләр гел башкача:
Төзекләнде юллар, авыллар.
Хәтта халык үзе күркәмләнде,
Мулрак була бара табыннар.

Яңа юлдан, яңа күпер аша
Очып кына килдем Нурлатка.
Килеп керү белән бер могҗиза
Пәйда булды. Сүзем шул хакта.

Иске йортлар торган бу авылны
Шәһәр иткән күпме төзелеш.
Соң елларда үскән зур биналар
Кертә моңа шактый зур өлеш.

Яшьләргә дә, картларга да җитә
Чын күңелдән чыккан игътибар.
Тырыш хезмәттән соң әйдә, ял ит —
Булсын гына моңа ихтыяр.

Бу җирлектә күпме милләт булса,
Бар да бии, җырлый үзенчә.
Район халкы бердәм, булган икән,
Хакимият башы сүзенчә.

## IV. «Эштән туймадым»

— Яхшы атлар кыңгыраусыз булмый,
Мин дә гел фәрештә булмадым.
Уртак эшкә зыян китергәннең
Башларыннан сыйпап тормадым.

Гөнаһларны Ходай ярлыкасын —
Хаҗ юлларын кайттым бер урап,
Миннән разый булмый калганнарның
Кичерүен мең кабат сорап.

Ни кылсам да, халык дип тырыштым.
Беркайчан да эштән туймадым.
Зур эшләрдә «өстән» ярдәм күрдем,
Һичбервакыт кагылу тоймадым.

*Фатыйх Сәүбән улының үз авызыннан*

«Авыллардан башка шәһәр юк ул —
Авылларны әүвәл кайгыртыйк»
Дигән шигарь белән йөри башлык,
Һәрбер гамәл өчен ут йотып.

Чын дусларга таяна ул һәрчак,
Ышанычлы бигрәк кулдашлар.
Үзе белеп эшли торган бар да —
Ни эшлим дип көтеп тормаслар.

Инде ничә еллар ул беренче
Төрле эштә, төрле өлкәдә.
Бүгенгесен имин уздырганга,
Ышанычы арта иртәгә.

Бу дөньяда иң борчыган нәрсә —
Тәмамланып бетми калган эш.
Ә синең эш һаман уңай килсен,
Хезмәтеңә күрә хөрмәт иңсен,
Сибагатуллин Фатыйх Сәүбәныч!

*2003*

# Каз өмәсе

*(Сәхнә өчен)*

Сәхнә өй итеп бизәлә. Пәрдә ачылганда, «Яуширмәм»[1] җыры яңгырый. Шул фонда алып баручы сүзен башлый.

А л ы п  б а р у ч ы.

Безнең авыл бик борынгы —
Яуширмә[2] дип атала,
Уңган-булган халкы белән
Гомер буе мактала.

Кызларыбыз чибәр, уңган,
Кызлар түгел — зилзилә,
Егетләр дә йоклап йөрми —
Җитмеш төрле эш белә.

Көзләр саен каз үстереп,
Җыелабыз өмәгә,
Эшлибез дә, җырлыйбыз да,
Гаҗәп оста гармунчыбыз
Бассын гына төймәгә.

Табын тулыр ризык белән
Эш беткәч сыйланырбыз,
Өмә тизрәк бетсен диеп,
Җәһәтрәк кыйланырбыз.

Бүген бездә каз өмәсе —
Шаулар, гөрләр өебез,
Бабалардан калган йола —
Тарсынмыйча килегез.

---

[1] Һәр авылда үз авылына яки районына багышланган җырны куярга мөмкин.
[2] Һәркем үз авылының исемен әйтә.

Өй хуҗасы Асыл апа
Хәзер кайтып та җитәр.
Кызларын алырга китте —
Бергәләп эш тиз үтәр.

Чү!
Кемдер бу табан йөгерә,
Асыл апа түгелме?
Ул икән шул!
Болай булгач, безнең өмә
Хәзер башланып та китәр,
Үтәр бик тә күңелле.

Кызы Ф ә й р ү з ә һәм берничә бала белән А с ы л а п а килеп керә.

А с ы л а п а.

Бүген безнең эшебез күп:
Казларыбыз бихисап,
Берни дә эшләнми калыр,
Авызны ачып торсак.

*(Кызы Фәйрүзә белән балаларга карап.)*

Фәйрүзәкәй, үзең белән
Ал да бу балаларны,
Дәшеп кайтыгыз өмәгә
Кызларны, апаларны.

И балалар, туктагыз,
Эшегез уңсын өчен,
Менә сезгә күчтәнәч —
Конфетлар белән күмәч.

Асыл апа балаларга күчтәнәчләрен өләшеп чыга. Фәйрүзә белән балалар чыгып китә.

А с ы л   а п а *(әйберләрне барлап).*

Шөкер, Аллам, бар да әзер:
Казлар да тезелешкән,
Су да кайткан, мич тә яккан,
Кызлар да эшкә тотынып
Килеп керә-керештән.

*(Тәрәзәдән карап.)*

Рәхмәт яугырлары, килеп тә җиттеләр.
Хәзер ачам ишекне, хәзер, хәзер!

Барып ишекне ача. Ф ә й р ү з ә һәм балалар белән к ы з л а р, а п а л а р килеп керә. Шау-гөр килеп күрешәләр, өсләреннән җылы киемнәрен салып, алъяпкычлар, яулыклар бәйлиләр. Күчтәнәчләрен бирәләр.

А с ы л   а п а.

Керегез, керегез әйдә,
Хуш килдегез, узыгыз,
Саумысыз борчагыз да,
Сезне күрүемә шат,
Утырышыгыз иркенләп,
Син монда утыр Гөлшат.
*(Урын күрсәтә.)*

Б е р е н ч е   х а т ы н.

Хәлең ничек, Асылбикә?
Сиңа бераз күчтәнәч:
Суынып та өлгермәде,
Мичтән чыккан ак күмәч.

А с ы л   а п а.

Бик рәхмәт, якын иткәч.

И к е н ч е х а т ы н.

Ә мин сиңа, ахирәтем,
Китердем сәйлүн чәе,
Курадан тәмле кайнатма.
Мунчадан соң рәхәтләнеп
Эчәрсез тирләп, яме.

А с ы л а п а.

Рәхмәт, рәхмәт, ахирәт,
Узыгыз, утырыгыз.
Казыгыз җиңел йолкынсын,
Мин бик риза, өебезне
Мамыкка тутырыгыз.

Бар да эшкә керешә. Тиз генә үтүк табып, аны кыздыралар. Каз өстенә юеш чүпрәк ябалар да үтүк белән бастырып-бастырып алалар. Пар күтәрелә. Парланган мамык тиз йолкына.

Б е р е н ч е х а т ы н.

Кая әле, Әлфия,
Бу казны да өт әле,
Син минем эшләремне дә
Җиңеләйтеп кит әле.

Әлфия аның казын парландырып бирә. Һәрберсенә каз әзер булгач, тезелешеп утыралар да С.Сәйдәшевнең «Өмә» җырын җырлый-җырлый, каз йолкырга керешәләр. Йолкып бетергән һәрберсе эчен чистарта башлый. Асыл апа кирәк-яракларны әзерләп, ярдәм итеп йөри. Балаларга каз куыклары бирәләр. Алар шуның белән мәш килә: куыкларны берәве өреп тора, икенчеләре башларын җеп белән бәйләп куя. Аннары аларны очырта-очырта уйныйлар. Берәрсенең торып киткәнен сагалап, утыргычына, җәймә астына куеп китәләр. Әйләнеп килгән кыз берни абайламый кала, килеп утыруга «шарт» иткән тавышка бар да сискәнеп китә. Аннан эшнең нидә икәнен сизеп алып, бар да шаркылдап көлә. Оятка калган кыз кызарып, уңайсызланып тора. Аннан балаларга ачулы-елмаюлы караш ташлап:

— Ах, шаяннар, наяннар,
Ярый әле сабырмын.
Янә шулай кыйлансагыз,
Тотармын да үзегезнең
Котыгызны алырмын. *(Бармак яный. Янә эшенә керешә.)*

Галия исемле кыз.

Кызлар, эшегез беттеме?
Бетсә, киттек бәкегә,
Казлар тынчып тормасын,
Юып кайтыйк йәт кенә[1].

*(Җыеналар, киенәләр. Җыенып бетә алмаган бер кызны күреп).*

Гөлнур, көянтәңне ас,
Менә сиңа ике каз.
Чиста булсын казларың,
Данын сатма кызларның.

Гөлнур да, тиз-тиз җыенып, казларын көянтәгә асып, башкалар артыннан чыгып йөгерә.

Асыл апа.

Ягез әле, балалар,
Уеннан туктап торыйк.
Казлар кире кайтканчы,
Бүлмәне җыеп куйыйк,
Бәлеш тә пешеп чыгар,
Чәебез кайнап торсын,
Егет-кызлар кайтуга
Бары да әзер булсын!

---

[1] Йәт кенә *(мишәрчә)* тиз генә.

Бүлмәне ялт иттереп җыештырып куялар. «Гармун»[1] җыры яңгырый. Өстәл әзерләнә. Самавыр, бәлеш, тәлинкә, кашыклар куела. Өстәл әзер булуга, кызлар, егетләр килеп керә. Чишенәләр, өстәл янына утыралар. Асыл апа сыйлап йөри.

Асыл апа.

Кара инде бу өстәлне —
Ни генә юк бит монда:
Бәлеш, өчпочмак, пәрәмәч,
Яңа аерткан каймагы,
Катык, сөте дә шунда.

Әйдә, кызлар, әйдәгез,
Рәхәтләнеп чәйләгез.
Аннан күңел ачарбыз,
«Кич утыру» ясарбыз.

*(Бер читтәрәк читенсенеп торган егетләргә карап.)*

Утырыгыз, егетләр,
Сыйланыгыз сез дәген.

*(Бер егетне күреп алып.)*
Кара, Әлфис, синме бу,
Нигә иртүк килмәдең?
Булышкан булыр идең,
Ярый, утыр, тиргәмим.

Бар да утырышып, көлешә-көлешә чәй эчеп, бәлеш ашап алалар.

Әлфия.

Кызлар, булды, торыгыз,
Җитәр инде, туегыз,
Эчмәгән чәегез түгел,
Тизрәк эчеп куегыз.

---

[1] Ф.Тарханова шигыре, Габдерәзак Мингалиев музыкасы.

Мирбулат, кайда гармун?
Тарат өйгә сихри моң.
Үтеп керсен үзәккә,
Дәрман бирсен йөрәккә.

Мирбулат гармун алып килә. Җыр башлана. Җырны бар да эләктереп ала. Күңелләренә хуш килгән җырлар җырлана. Балаларны, бераз утыргач, йокларга озаталар. Җыр беткәч, уеннар башлана. «Йолдыз санау», «Күгәрчен ашату» кебек җәза бирелә торган башка уеннар. Шул уеннар вакытында җәза рәвешендә җырлаталар да, биетәләр дә. Соңыннан барысы бергә (күмәк) бииләр. Биюләр тәмам булгач, Асыл апа уртага чыга.

Асыл апа.

Никадәр зур эш эшләнде,
Күңелләр дә хуш булды.
Җырлашып биеп тә алдык,
Җаннарга да нур тулды.

Зур рәхмәт сезгә, егетләр,
Кызлар, сезгә бигрәк тә,
Рәхмәтләрнең иң кәттәсен
Әйтәмен чын йөрәктән.

Кул-аягыгыз сызлаусыз
Булсын иде дип телим.
Күңелләрем ташып тулды —
Ни әйтергә дә белмим.
Һәммәгезгә дә кучтәнәч
Әзерләп куйган идем.

*(Өстәлнең бер почмагында өелгән кучтәнәчләргә күрсәтә.)*

Алыгыз әле, ал, зинһар,
Каяле, үзем бирим.
Кучтәнәчләр белән бергә
Изге теләкләр телим.

Барысына да кучтәнәч өләшеп чыга. Егетләрнең кайберсе үз кучтәнәчен яраткан кызына бирә. Алып баручы чыга.

А л ы п   б а р у ч ы.

Бүген безнең өмә көне —
Шатлыгыбыз бер кочак.
Инде менә сиздермичә
Килде саубуллашыр чак.

*(Егет-кызларга карап.)*

Дусларым, мин дә әйтәмен
Рәхмәтләрнең зурысын.
Киләсе елда да казлар
Күп булып үсеп куйсын.
Һәр ел саен җыелышып
Уздырыйк өмәләрне.
Чакырганны да көтмичә,
Үзегез килегез, яме.

*(Өмәдә катнашучыларга да, тамашачыларга да карап.)*

Хушыгыз, сау булыгыз,
Исән-имин торыгыз.
Гөл-чәчкәләргә күмелсен
Сезнең йөрер юлыгыз!

Эшегез һәрчак уңсын,
Күңелләргә моң тулсын.
Киләсе елда да безгә
Очрашу насыйп булсын!

Саубуллашу җыры яңгырый. Барлык катнашучылар да җырга кушыла һәм, соңгы кушымтаны җырлый-җырлый, сәхнәдән кереп китәләр.

Дөнья күркәм, тормыш бүтән
Янда дуслар булганда,
Кирәк чакта хәл белешеп,
Гел күрешеп торганда.

Кушымта:
Әйдә, дуслар, җырлыйк әле,
Өздереп биеп алыйк,
Серле моңнардан дәртләнеп,
Яшьлектә яшьнәп калыйк.
Бер — яшьлектә, бер — картлыкта:
Яшьлек дәртендә яныйк.

Бергәлектә — көч, диләр бит,
Бергә яшәек әле,
Бер-беребезгә елмаешып,
Сөеп дәшәек әле.

Кушымта.

Санаулы вакыт чамалы —
Җәлләми үтеп китте,
Аерылышу минуты да
Әйләнеп килеп җитте.

Кушымта.

Һәр очрашу — бик зур бәхет,
Кавышуларга илтә,
Сагыну да алай түгел,
Хушлашулар тилмертә.

Сау булыгыз, бай торыгыз,
Гомерләр имин үтсен,
Алдагы көндә дә Ходай
Очрашу насыйп итсен!

Кушымта.

*2000*



# Эчтәлек

## I. И Туган як!

Яуширмә ........ 5
Сагыш ........ 6
Гармун ........ 10
Әниемнең авыру хәбәре ........ 11
Алсу сеңлемә ........ 12

## II. Күңелемне борчый...

Бөек идеяләр чоры узды ........ 17
Мин кайтарыр идем... ........ 18
Унтугызынчы йөз кешесемен ........ 19
Ханбикәне «уйнап» булмады ........ 20
Күзләремә һаман яшь тула ........ 22
Ары табан... ........ 23
Матриархат ясап... ........ 25
Дус булып йөрүчегә ........ 27
Бу ни җанвар? ........ 28
Бүре гел йөреп тора ........ 29
Буш куык ........ 30
Күрик, әйдә, бары яхшылыкны! ........ 33
Башлык ........ 34
Туйда котлау ........ 36
Сер бирмәгез! ........ 37
Быел җәйдә ........ 38
Татар сые ........ 40
Елмаеп яшик ........ 41
Ярый әле судья бар! ........ 42
Маймыл елы ........ 43
Керфегем дә селкенми ........ 44
Тагын кая киттең син, Рәсәй? ........ 45
Бөгеп булмас бөек татарны ........ 47
Сау булыгыз! ........ 48

## III. Багышлаулар

Исхакый ... 51
Клеопатра ... 52
Канәтем ... 54
Фәтанәт кыйссасы ... 55
Син яшьлектән әле китмәгән ... 57
Килеп чыгарсың күк тоела ... 58
Галәмнәргә барып тоташкан ... 59
Сәйдәш моңнары ... 60
Соңгысыдыр диеп белмәдем ... 61
Диләрә ... 63
Кайтам әле, кайтам Сабаларга ... 65
Чакмагыш ... 66
Мәскәүләргә барган идем әле ... 67
Килеп чыктым Нурлат якларына ... 68
Нурлатым ... 69
Яшьлегем сукмаклары ... 70
Казан турында ода ... 71
Борынгыдан килә Казаным! ... 73
Ташлап китмә, Сөембикәм! ... 74

## IV. Хисләр дәрьясында

Бәхет көттем мин ... 77
Хатларыңны укып чыктым... ... 78
Төшкән иде синең яктылык ... 80
Сине сагынып үтә гомерем ... 81
Әллә нигә җаным сызлана ... 82
Гомерлек ярым ... 83
Онытырасың килмәсә... ... 84
Тыңла йөрәк тибешен ... 85
Булдым инде таңда бер Чулпан ... 86
Гөлләр бакчасында ... 87
Куймас микән богаулап? ... 88
Йолдыз булдың гомер күгемдә ... 89
Борчылма син ... 90
Чыкты да алларыма... ... 91
Бөдрә сирень ... 92
Багышлау-нәсыйхәт ... 93
Соңарып килгән сөю ... 95
Пәри кызы ... 106
Бер карасаң... ... 107
Хатларыңда яздың миңа... ... 108
Керфек өсләреңдә чатыр корып... ... 109
Яныңда кеше булса соң... ... 110
Яулап алдың бугай ... 111

Тәгълимнамә .......... 112
Истанбул гөлләре .......... 113
Бүлмәм саен элдем рәсемеңне .......... 114
Тик хатларың никтер тоткарланды .......... 115
Җылы яңгыр булып сибәли .......... 116
Нигә кирәк сиңа минем сөю? .......... 117
Әллә яратам инде? .......... 118
Эзлим .......... 119
Куркытма! .......... 120
Яратышу булмаса... .......... 121
Сискәнеп куйдыңмы? .......... 122
Нишләрем? .......... 123
Кочагыңа алып сөйсәң... .......... 124
Әллә инде чынлап үпкәләдең? .......... 126
Хәерле юл! .......... 127
Кемнәр бәйләде? .......... 128
Илгә күрендем инде .......... 129
Хәтерлимсең? .......... 130
Юлыңнан минсез китәрсең .......... 131
Бигайбә .......... 132
Ни он суы, ни тоз суы... .......... 133
Бер канатым сынык икән лә... .......... 134
Сәрләүхәсез .......... 135
Ялвару .......... 137
Рәсем .......... 139
Гәпләшәсем килә утырып .......... 140
Ярлыкагыз мине! .......... 141
Сөюне керткән идем .......... 142
Кышкы озын кара төннәрдә .......... 143
Үзең тагын килдең төшләргә .......... 144
Әле яңа гына .......... 145
Нигә җебеп утырасың әле? .......... 146
Хәтерләргә уелып калырлар .......... 147
Ни мәгънә соң? .......... 149
Ничә еллар... .......... 150
Хәерлегә булсын! .......... 151
Фарсы белән аралаш .......... 152
Сөю китермәгән назлар нигә? .......... 154
Аралагыз сез мине .......... 155
Күпме көттем .......... 156
Син юк инде бүген минем янда .......... 157
Китә калсам .......... 158
Мин озаттым сине .......... 159
Кирәгең бетте инде .......... 160
Газәлләр .......... 161
«Суга иелгән талларга...» .......... 162

«Иреннәрең балдан татлы» .................... 163
«Матур җәйдә...» .................... 164
«Саф йөрәккә...» .................... 165
«Мин Ходайдан күпме үтендем...» .................... 166
«Затлы күлмәгемне кидем...» .................... 167
«Чын сөюне татымаган...» .................... 168
«Җан кисәгем...» .................... 169
«Авыр уйдан арына күр...» .................... 170
«Дисталәгән ел үтсә дә...» .................... 171
Дүртьюллыклар .................... 172
Робагыйлар .................... 174
Шаян такмаклар .................... 178

**Поэмалар**

Кремль диварлары янында .................... 188
Капка .................... 193
Беренче сентябрь хатирәсе .................... 200
Хезмәтенә күрә хөрмәте .................... 205
Каз өмәсе .................... 210

Литературно-художественное издание

*Тарханова Флёра Габдрахмановна*

**Тропинки моей юности**

Стихи, песни, поэмы

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Т.В.Пашагина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.10.2005.
Форматы $70 \times 90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,19 + форз. 0,15 .
Шартлы буяу-оттиск 17,25. Нәшер-хисап табагы 7,09 + форз. 0,26.
Тиражы 5000 д. Заказ А-746.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
ГУП Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.